Туган телем - иркә гөлем, киңдер сиңа күңел түрем...

КҮЛӘК КӨЧ

ГОМУМИ РАЙОН
ТАТАР ГАЗЕТАСЫ
1930 елдан чыга.
Бәясе ирекле
№ 49 (10689)
Чәршәмбе,
7 декабрь 2016 ел.
(Атнага бер тапкыр чыга)

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫЛАР: 1. УЛЬЯНОВСК ӨЛКӘСЕ ХӨКҮМӘТЕ (432017, Ульяновск шәһәре, Ленин мәйданы, 1)2. "ИСКЕ КУЛАТКЫ РАЙОНЫ" МУНИЦИПАЛЬ БЕРЛӘШМӘСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ (433940, УЛЬЯНОВСК ӨЛКӘСЕ, ИСКЕ КУЛАТКЫ ЭШЧЕЛӘР БИСТӘСЕ, ПИОНЕРСКАЯ УРАМЫ, 30)

АЛАРДА САБЫРЛЫК, ЯШӘҮ КӨЧЕ БАР

Ел саен Россиядә җәмәгатьчелек игътибарын мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр проблемаларына җәлеп итү максатыннан Халыкара инвалидлар көне билгеләнә.

Кешеләрнең мондый хәлгә калуында беркем дә гаепле түгел, мәсәлән, кеше тумыштан инвалид яисә төрле авырулар, бәхетсез очраклар нәтиҗәсендә инвалидлыкка дучар булырга мөмкин. Шул сәбәпле, алар дәүләт тарафыннан өстәмә ярдәмгә, аерым игътибарга мохтаҗ.

Сәламәтлекләре ягыннан ярдәмгә мохтаҗ балалар да тулы һәм лаеклы тормышта яшәргә, белем алырга, бушлай медицина ярдәменнән файдаланырга тиеш.

Балалар һәм үсмерләр өчен реабилитацияләү үзәге-менә шундый мөмкинлекләре чикләнгән сабыйларга һәм аларның ата-аналарына киләсе көнгә өмет һәм яшәү көче бүләк итүче дәүләт учреждениеләренең берсе булып санала.

2 декабрь көнне районыбызда эшләп килүче “Парус Надежды” инвалидларны реабилитацияләү бүлеге тарафыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен “Күңелле стартлар” дип исемләнгән спорт ярышлары оештырылды. “Парус Надежды” бүлеге җитәкчесе Зөлфия Аксәнова, белгечләр Фирүзә Бимеева белән Динара Сабитова һәм “Гаилә” үзәге педагогы Диана Салихова уеннарда катнашучы һәрбер балага индивидуаль рәвештә ярдәм күрсәттеләр. Ярышларда балалар рәхәтләнеп күңел ачтылар һәм җитезлектә, тапкырлыкта көчләрен сынадылар.

Иске Кулаткы районында 34 гаиләдә мөмкинлекләре чикләнгән 35 бала тәрбиәләнә. Шуларның 25 се мәктәптә укый, 8 се мәктәпкәчә яшьтәге балалар. Алар барчасы да халыкны яклау органнарында исәптә тора. Әлеге гаиләләргә тиешле ярдәм күрсәтү, сәламәтләндерү буенча барлык тиешле чаралар күрелә. Мөмкинлекләре чикләнгән балаларга социаль пенсия түләнә. 1995 елның 24 ноябрендә кабул ителгән”РФ инвалидларны социаль яклау” турындагы 181 нче номерлы Федераль закон нигезендә инвалидларга социаль пакет белән куллану хокукы бирелә. Социаль пакетка табибларның рецептлары буенча тиешле дарулар белән тәэмин итү, медицина күрсәтмәләре буенча санатор-курорт дәвалау йортларына 2 путевка (икенчесе озатып баручы өчен) бирелә һәм дәвалану урынына бушлай барып кайту каралган. Инвалид балалары булган гаиләләр торак-коммуналь хезмәтләрен түләү льготалары, шулай ук бушлай медицина, социаль, педагогик һәм реабилитацияләү хезмәтләре белән тәэмин ителәләр. Гамәлдәге закон нигезендә, картлык буенча вакытыннан алда хезмәт пенсиясенә чыгу хокукы баланың күпме вакыт инвалид булуына карамастан, балачактан инвалид баласы булган, аны 8 яшькә кадәр тәрбияләгән ата-ананың берсенә: ирләргә – 55 яшькә, хатын – кызларга 50 яшькә җиткәч бирелә. Ләкин моның бер шарты бар: иминият стажы ирләрнең - 20 ел, хатын – кызларның 15 ел булырга тиеш. Баланың ничә яшьтә инвалид дип табылуы ата - ананың льготалы пенсиясенә тәэсир итми. 18 яше тулмаган инвалид бала тәрбияләүче гражданнарга социаль компенсацияләр түләнә. Инвалид балалары булган ата-ананың берсе, гариза нигезендә, ай саен түләүле 4 ял көне алырга хокуклы. Имтиханнарын уңышлы тапшырган инвалид балалар уку йортларына конкурстан тыш кабул ителәләр. 2012 елның 1 январеннан инвалид балага 300 сум күләмендә ай саен пособие түләнә. 2011 елдан кабул ителгән “Ульяновск өлкәсендә демографик хәлләрне уңайлату” законы нигезендә регионыбызда яшәүче мөмкинлекләре чикләнгән балалар тәрбияләүче гаиләләр социаль хезмәткәрнең ярдәме белән кулланырга хокуклы. Бүгенге көндә районыбызда яшәүче ике гаилә әлеге уңайлыклар белән куллана инде. Район депутатлар Советының карары буенча 3 мөмкинлекләре чикләнгән бала мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә бушлай йөриләр. Агымдагы елда 6 инвалид бала техник реабилитацияләү чаралары белән тәэмин ителде. Мөмкинлекләре чикләнгән балалар әниләре белән Анапа шәһәренең “Парус” санаторийсында, Димитровград шәһәренең “Сосновый бор” социаль реабилитацияләү үзәгендә һәм “Березка” санаторийсында бушлай путевкалар буенча дәваландылар. Инвалидлар үткәнлеге кысаларында Иске Кулаткы социаль яклау идарәсе хезмәткәрләре “Яхшылык эшләргә ашыгыгыз!” акциясен үткәрделәр. Мөмкинлекләре чикләнгән балаларны шатландыру – әлеге акциянең төп максаты булып кала. Райондашларыбызның һәркайсы акциядә катнашып, инвалид балаларга яки өлкәннәргә хәленнән килгән кадәр ярдәм күрсәтә ала. 6 декабрь көнне районыбызда эшләп килүче “Парус Надежды” инвалидларны реабилитацияләү бүлегендә мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен “Тормышның салават күпере” дип исемләнгән бәйрәм оештырылды. Балалар әлеге күңелле бәйрәмдә зур теләк белән катнаштылар.

Ә.М. ШАБАКАЕВА,
Халыкны социаль яклау идарәсенең бүлек мөдире.

ПӘНҖЕШӘМБЕ (08.12.)	ҖОМГА (09.12.)	ШИМБӘ (10.12.)	ЯКШӘМБЕ (11.12.)	ДҮШӘМБЕ (12.12.)	СИШӘМБЕ (13.12.)	НӘРШӘМБЕ (14.12.)
- 18 / - 12	- 9 / - 7	- 4 / - 8	- 6 / - 12	- 12 / - 15	- 18 / - 25	- 16 / - 19

ЯҢАЛЫКЛАР

Яңа сайланган АКШ Президенты Дональд Трамп “җаваплылыкның яңа дәрәҗәсенә” ия булуын аңларга тиеш. Бу хакта Россия Президеты Владимир Путин НТВ каналында “Итоги недели” программасында әйтте, дип хәбәр итә ТАСС. “Бизнеста уңышка ирешә алуы аның акыллы кеше икәнлеген раслый. Ә акыллы кеше җаваплылыкның яңа дәрәҗәсе турында да тиз төшенәчәк”, - диде Путин. «Без аның шул позицияләрдән чыгып эш итүенә фараз кылабыз”, - диде Россия Президенты.

● ● ●

Россия Президенты В.В. Путин Ханты-Мансийск автоном округы – Югра губернаторы Наталья Комаровага кайгы уртаклашу мөрәҗәгатен юллады.

Мәгълүм булганча, 4 декабрьдә Төмән – Ханты-Мансийск автомобиль юлында автобус, ике җиңел машина һәм йөк машинасы бәрелешүе нәтиҗәсендә, 12 кешенең гомере өзелде. Аларның 11е - балалар. Соңгы мәгълүматлар буенча, 18 бала авыр хәлдә хастаханәдә ята. 5 декабрь матәм көне булып игълан ителде.

● ● ●

Россия Президенты Владимир Путин Россия Федерациясе Федераль Җыенга еллык юллама белән чыгыш ясады.

Президент әйтүенчә, үзенең юлламасында ул иң беренче чиратта икътисадка басым ясады. "Гражданнар берләшкәннәр – аларга моның өчен рәхмәт, алар барысы белән риза булмасалар да, ватанпәрвәр кыйммәтләр тирәсендә берләшкәннәр. Кыенлыклар җитәрлек, ләкин сәбәпләрен аңлыйлар. Бик зур рәхмәт аларга. Халык аларга, аларның хокукларына, азатлыкка һәм хезмәткә карата ихтирамлы булуына исәпли."



6 декабрьдә Губернатор Сергей Морозов атом энергиясе буенча яңа Информацион үзәк ачылу тантанасында катнашты. Әлеге чара В.И. Ленин исемендәге өлкә фәнни китапханәсендә үтте.

● ● ●

Регион Башлыгы Сергей Морозов йөкләмәсе белән 2017 елда эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү буенча программаларны тормышка ашыру дәвам итәчәк. Эшмәкәрлек өлкәсен үстерү турында Россия Президенты Владимир Путин Федераль Җыенга еллык юлламасында билгеләде.

● ● ●

5 декабрьдә Ульяновск дәүләт педагогия университетында Бөтенроссия “Яхшылык сәгате” акциясе кысаларында “Яхшылык дәресе” проекты оештырылды. Әлеге чарада Губернатор С.И. Морозов һәм программалаштыру клубларының әгъзалары катнашты.

● ● ●

Регион Башлыгы Сергей Морозов Ульяновск өлкә клиник больницасы коллективын учреждениенең 215 еллыгы белән тәбрик итте. Очрашу дәвамында эшләрендә зур уңышларга ирешүче хезмәткәрләр тантаналы рәвештә билгеләнделәр.

ИНФОРМАЦИОНОЕ СООБЩЕНИЕ

В Ульяновской области будет создана Дирекция по подготовке инфраструктуры города Димитровграда и Мелекесского района к сдаче высокотехнологичного центра медицинской радиологии

Такое поручение дал Губернатор Сергей Морозов на аппаратном совещании в понедельник.

«Мы специально посвятили всё лето большой работе с федеральным Правительством, Администрацией Президента. Искренне рад, что и Президент, и Премьер поддержали все наши и ФМБА наработки. Это федеральный объект, строится на федеральные средства. Со своей стороны все региональные и муниципальные обязательства мы выполнили. На прошлой неделе Председателем Правительства РФ принято решение о выделении финансовых средств в размере 2,8 миллиарда рублей на приобретение 964 квартир для работников ядерного медицинского центра», - сказал Губернатор.

Напомним, медицинский центр будет обслуживать как жителей Ульяновской области, так и других субъектов РФ. Окончание строительства всех 26 корпусов Центра – первый квартал 2019 года. В декабре этого года будет сдан ПЭТ-центр, на площадке уже работает аптека – научный блок с производством новых персонифицированных лекарственных форм. В феврале 2017 года будет дан физический «пучок», в апреле состоится биологический пуск по биологическому манекену, а летом 2017 года будет возможность принять первого пациента. Глава региона отметил, что в связи с окончанием строительства Центра медицинской радиологии будет создана специальная Дирекция по подготовке инфраструктуры города Димитровграда и Мелекесского района, которую возглавит первый заместитель Председателя Правительства Ульяновской области Александр Смекалин.

«Мы выходим на финишную прямую. Для этого нужно ускорить подготовку кадров, строительство жилья и социальной инфраструктуры. Крайне важно уделить особое внимание культурной и социальной политике в этом муниципалитете. В ближайшее время мы проведём совещание, куда пригласим и представителей общественных организаций, и активных граждан. Там утвердим состав Дирекции, после чего она приступит к работе в Димитровграде», - подчеркнул Сергей Морозов.

Для справки

Проект по созданию центра медицинской радиологии реализуется на территории Димитровграда по государственной программе «Создание федеральных центров медицинских радиологических технологий» в рамках исполнения поручения Президента РФ. В структуру учреждения входят более двадцати корпусов, среди которых и протонный центр. Всё медицинское учреждение рассчитано на посещение более 20 тысяч больных в год и будет включать в себя клинический стационар примерно на 400 мест, реабилитационный корпус, здание радионуклидной диагностики, а также поликлинику на 240 посещений в смену.

В УЛЬЯНОВСКОЙ ОБЛАСТИ ИНТЕНСИВНО РАЗВИВАЕТСЯ IT-ИНДУСТРИЯ

Сначала года число профильных компаний, зарегистрированных в Министерстве связи и массовых коммуникаций РФ, увеличилось вдвое: с 40 до 80. Всего в регионе в сфере информационных технологий работает свыше 150 организаций.

1 декабря в своём Послании Федеральному Собранию Президент России Владимир Путин подчеркнул важность развития IT-сферы.

«Одной из самых быстроразвивающихся отраслей стала у нас, уважаемые коллеги, IT-индустрия, что очень радует. Объём экспорта отечественных компаний за пять лет вырос вдвое. Я сейчас приводил цифры объёма экспорта «оборонки», сельхозпродукции. «Оборонка» – это 14,5 миллиарда. Совсем недавно IT-технологии составляли цифру, которая приближалась к нулю, сейчас – 7 миллиардов долларов», - подчеркнул Владимир Путин.

Напомним, в Ульяновской области по поручению Губернатора Сергея Морозова реализуется комплекс мер, направленных на создание благоприятных условий для IT-компаний.

«Мы уже давно сделали ставку на развитие сферы информационных технологий, поскольку понимаем, что от этого напрямую зависит и работа остальных отраслей, и качество жизни людей. У нас сформирован IT-кластер, ульяновские IT-компании известны далеко за пределами страны, неоднократно входили топ в российских и международных рейтингов. Мы ввели ряд налоговых льгот для этих организаций, а также комплекс мер по обеспечению отрасли высококвалифицированными кадрами. Речь идет и о привлечении в IT-сферу талантливых ребят, и об их социальной поддержке», - подчеркнул глава региона.

Напомним, в 2016 году по поручению Сергея Морозова в Ульяновской области введена система налоговых льгот для IT-компаний. Так, с 6% до 1% снижены ставки для аккредитованных в Минкомсвязи организаций, работающих по упрощенной системе налогообложения, если объектом налогообложения являются доходы. С 15% до 10% уменьшены налоговые ставки для всех ИТ-компаний, работающих по упрощенной системе налогообложения, если объектом налогообложения являются доходы, уменьшенные на величину расходов. С 15% до 5% сократились ставки для субъектов малого и среднего предпринимательства, если объектом налогообложения являются доходы, уменьшенные на величину расходов (в течение двух налоговых периодов). Для впервые зарегистрированных предпринимателей, работающих по патентной системе налогообложения и оказывающих услуги по ремонту компьютеров и коммуникационного оборудования действует нулевая налоговая ставка.

Также ульяновским ИТ-специалистам предоставляется единовременная социальная выплата в размере 50% первоначального взноса по ипотечному кредиту в сумме до 150 тысяч рублей.

Президент России Владимир Путин обозначил важность поддержки IT-компаний. Напомним, для организаций, прошедших аккредитацию в Министерстве связи и массовых коммуникаций РФ, предусмотрена пониженная налоговая ставка в размере 13,5%. В Послании к Федеральному Собранию глава государства выступил с инициативой продлить данные льготы до 2023 года.

«Эта мера позволила им эффективно реализовать свой интеллектуальный новаторский потенциал. Смотрите, в начале пути, в 2010 году, их налоговые отчисления составляли 28 с небольшим миллиардов рублей, а через два года – уже 54 миллиарда рублей. Представляете, какой рост! При этом так называемые выпадающие доходы, с учётом льгот, всего 16 миллиардов рублей. То есть реальный доход даже для бюджета. Чтобы поддержать такую динамику, предлагаю продлить эти льготы до 2023 года. Уверен, уже в ближайшее десятилетие есть все возможности сделать IT-индустрию одной из ключевых экспортных отраслей России», - отметил Владимир Путин.

Напомним, вопросы развития IT-кластера и информатизации Ульяновской области курирует Корпорация развития информационных технологий, созданная в августе этого года по распоряжению Губернатора.

«IT-компании региона продолжают испытывать потребность в профессиональных кадрах, ежегодно им требуется 400-500 специалистов. Мы далеко не первый год работаем над подготовкой высококвалифицированных кадров, а также над популяризацией IT-профессий среди подрастающего поколения. В регионе проводятся бесплатные курсы повышения квалификации как для студентов, так и для преподавателей школ. На базе государственных учебных заведений дошкольного образования создаются кружки, разрабатываются программы занятий для дошкольников, направленные на изучение математики, физики, информатики. Среди направлений обучения - робототехника, компьютерная анимация и lego-программирование. По поручению Губернатора на базе Корпорации развития ИТ будет организован проектный офис «Развитие IT-индустрии в Ульяновской области». Сейчас создаётся профильная группа, куда войдут представители регионального Минобрнауки, вузов, Ассоциации муниципальных образований Ульяновской области и IT-компаний. Цель – выращивать в регионе высококвалифицированные кадры для реализации перспективных проектов IT-индустрии», - пояснила директор ОГКУ «Корпорация развития ИТ» Светлана Опенышева.

Для справки

В декабре 2014 года утверждена Стратегия развития отрасли информационно-коммуникационных технологий и электроники Ульяновской области на 2015-2020 годы. Создание Фонда развития информационных технологий в 2016 году стало одним из пунктов по её реализации. Фонд финансируется из областного бюджета и из бюджета региональных ИТ-компаний. 11 проектов в сфере ИТ-образования выиграли гранты в 2016 году. В 2017 году на поддержку проектов, направленных на развитие человеческого потенциала в IT, Правительством региона будет выделено 5 млн рублей.

ИНФОРМАЦИОННОЕ СООБЩЕНИЕ

1. В соответствии с одной поданной заявкой и с п. 129 Приказа ФАС от 10.02.2010г. № 67 аукцион, открытый по составу участников и открытый по форме подачи предложений по цене, по лоту № 1 – заключение договора аренды на нежилые помещения №13,14,15, общей площадью 39,61 кв.м., расположенные на втором этаже здания по адресу: Ульяновская область, Старокулаткинский район, р.п. Старая Кулатка, ул. Куйбышева, д.22, который должен был состояться 29.11.2016 года в 11 час. 00 мин. в здании администрации по адресу: Ульяновская область, Старокулаткинский район, р.п. Старая Кулатка, ул. Пионерская, д.30, каб.204. признать несостоявшимся. Извещение о проведении продажи опубликовано в газете «Кумяк куч» от 26 октября 2016 года №43 (10683) и на официальном сайте www.torgi.gov.ru в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет». Продавец: администрация муниципального образования «Старокулаткинский район» Ульяновской области.

2.В соответствии с п. 151 Приказа ФАС от 10.02.2010 № 67 заключить договор аренды с единственным участником аукциона - ООО «Новая волна» на условиях, предусмотренных аукционной документацией, по начальной цене аукциона.

Администрация муниципального образования «Старокулаткинский район».

Информация

об итогах продажи муниципального движимого имущества находящегося в собственности муниципального образования «Старокулаткинский район» посредством публичного предложения с использованием открытой формы подачи предложения о приобретении муниципального имущества и открытый по составу участников, состоявшегося 29.11.2016 г. в 10 час. 13 мин. (время местное) в здании администрации по адресу:Ульяновская область, Старокулаткинский район, р.п. Старая Кулатка, ул. Пионерская, д.30, каб. 204. Извещение о проведении продажи опубликовано в газете «Кумяк кюч» от 26 октября 2016 года №43 (10683) и на официальном сайте www.torgi.gov.ru в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет».

Продавец: администрация муниципального образования «Старокулаткинский район» Ульяновской области.

Количество участников торгов -3.

Победителем продажи по Лоту №1 - автомобиль марки УАЗ ПАТРИОТ, 2005 года выпуска, наименование (тип ТС) - легковой, номер кузова - 31630060003037, идентификационный номер (VIN) – XTT31630060003037, цвет: авантюрин – металлик, паспорт транспортного средства 73 МА №169563 выдан ОАО УАЗ 16.12.2005г. признан участник №3- Архипов Александр Анатольевич. Последнее предложение о цене имущества заявлено участником №3- Архиповым Александром Анатольевичем на 2 шаге аукциона – 116 200 рублей (сто шестнадцать тысяч двести) руб., сложившуюся на 4 шаге понижения, последующей цены от участников торгов не поступило.

Администрация муниципального образования «Старокулаткинский район».

МӘҺИМ МӘСЬӘЛӘ

ДЕПУТАТЛАР ОТЧЕТ ТОТТЫЛАР

Чираттагы киңәйтелгән аппарат киңәшмәсендә районның барлык дәрәҗәдәге депутатлары халыкның сайлау алды наказлары буенча чыгышлар ясадылар. Һәр авылның үз проблемасы үз нужасы бар дигәндәй. Әлбәттә, бүгенге көндә иң актуаль район авылларында газлаштыруны төгәлләү булды.

Моның буенча район җитәкчеләре киеренке эш алып барсалар да, әлегә ул тулысынча үтәлеп беткәне юк. Тик өлкә Губернаторының программасында 2020 елга барлык авылларны да тулысынча газлаштырып бетерергә диелгән. Димәк, өч ел эчендә барысы да тормышка ашачак. Бүген Иске Зеленай поселениесендә ул эшләр алып барыла. Депутатлары М. З. Бекеров сөйләвенчә, Иске Зеленай авылында өй эчләрендә дә газлаштыру җиһазлары урнаштырылган, авыллар арасыннан да линияләр тартылган, тик газ бирәсе генә калган. Менә шуның документларын гамәлгә кертү белән шөгыльләнә бүген җитәкчеләр. Аннары чиратта Урта Терешка поселениесе, Иске һәм Яңа Яндука, Карамалы авыллары кала.

Бүген барлык авылларда да баганаларда электр утлары яна, район Советы депутаты, район Башлыгы Э.Ә. Ганеев үз малына сатып алып лампочкалар кайтарып тора, янган саен алмаштырта. Халык көзге караңгыда адашып йөрмәсен дип тырыша. Халык үз депутатлары аша аңа рәхмәт сүзләре җиткергән. Һәр чыгыш ясаучы моны искәртеп үтте. Иске Мостяк поселениесе депутаты М.М. Нугаев та: "Бүген Яңа Һәм Иске Мостяк авылларында яхшы яшәү өчен барлык шартлар да булдырылган" - диде, моның өчен шушы поселениедән сайланган депутат Э.Ә. Ганеевка халыкның рәхмәтен җиткерде. Эдуард Әнвәрович даими рәвештә үзенең сайлаучылары белән очрашып тора, аларның барлык сорауларын да тыңлый һәм үти.

Карамалы авылы халкы үзләренең депутатлары Р.Я. Яфаровка юл ясауны сорап, мөрәҗәгать иткән булганнар. Ул юлдан балаларны Иске Кулаткы икенче номерлы урта мәктәбенә укырга йөртәләр. Быел урман эчендәге өлешендә агачлар куерып, күз күремен начарайткан.

Иске Атлаш авылында 11 ноктадан ялган аракы сатып торалар икән, авыл халкы депутатларына мөрәҗәгать итеп, аларны яптыруны, халыкны агулауны соралганнар. Чөнки шушы ялган аракыны эчеп, бер көндә ике кеше дөнья белән хушлашкан. Район Советы депутаты Н.Р. Чамкаева барлык депутатлар белән бергә ул яман чиргә каршы көрәшергә чакырды. Шунысы аяныч сатучыларның начар гамәле турында эчке эшләр органнары сотрудниклары белән тиешле чараларын гына күрмиләр икән.

Югары Терешка авылы халкын элек су юклыгы борчыган булса, хәзер аларны юлларының начар булуы пошындыра. Шулай ук авылларына кайчанда булса, газ килер дип өмет итәләр. Ә менә Мосеевка авылында халык күптән инде газлы да, һәркайсының өенә су да кергән. Район Башлыгы Э.Ә. Ганеев суга кытлык күрмәсеннәр өчен яңа су линиясен дә ясатты. Тик авыл тирәсе чүп - чарга күмелгән. Төзекләндерү кирәк. Бу әлбәттә халыктан үзләреннән дә тора. Йорттан чыгарган чүплекне теләсә кайда, теләсә ничек ташларга гына кирәкми. "Кирюшкино авылында яшьләр тринажорлар, спорт инвентаре сорый", - дип чыгыш ясады район Советы депутаты Р.Н. Кузяев. Мәктәп спорт залына кичләрен 15 – 20 гә якын яшьләр җыела. Инешне туңдырып боз шугалагы ясыйлар, шунда шуарга тимер аяклар кирәк. Авылда Э.Ә. Ганеевның инициативасы белән ял итү үзәге ясалган. Тик гармунчының баяны юк икән.

Депутатлар ешрак халык янында булып, аларның яшәү шартлары, мәнфәгатьләре белән кызыксынып торырга, аларның аһ – зарын район җитәкчеләренә җиткереп торырга бурычлылар. Чөнки халык аларга ышаныч белдергән, аларга өмет баглыйлар.

Майзә МАСИЕВА.

ВЫПИСКА ВМЕСТО СВИДЕТЕЛЬСТВА

С государственной регистрацией прав на недвижимость сталкивался хотя бы раз в жизни каждый гражданин. До сих пор россияне дорожили своими свидетельствами, которые подтверждали их право собственности на дом, дачу, квартиру или земельный участок. Но с 15 июля текущего года выдача свидетельств на право собственности прекращена. Основанием для отмены служат поправки, внесенные в Федеральный закон «О государственной регистрации прав на недвижимое имущество и сделок с ним». Вместо свидетельства о государственной регистрации прав собственности на недвижимость выдается выписка из Единого государственного реестра прав на недвижимость и сделок с ним. С новыми изменениями у жителей региона возникло очень много вопросов. В данном материале мы постараемся ответить на наиболее частые вопросы собственников и развеять все сомнения относительно нового документа, выдаваемого вместо свидетельства.

Что это за документ – выписка из ЕГРП?

Выписка представляет собой документ, подтверждающий актуальность сведений об объекте недвижимости. Документ удостоверяет, что на указанную в нем дату выдачи за определенным лицом зарегистрировано право на конкретный объект недвижимости, о чем в ЕГРП в соответствующий день сделана регистрационная запись под соответствующим номером.

Какой срок действия выписки?

Выписка действует бессрочно, однако фиксирует положение дел с регистрацией прав на объект недвижимости именно на дату выдачи.

Сколько стоит выписка?

Документ можно получить как в бумажном, так и в электронном виде. Стоимость выписки из ЕГРП: в бумажном виде для физических лиц – 200 рублей, для юридических – 600.В электронном виде – 150 и 300 рублей соответственно.

Где и в какие сроки можно получить выписку?

- при личном обращении в орган кадастрового учета (Кадастровая палата);
- при личном обращении в многофункциональный центр предоставления государственных и муниципальных услуг Ульяновской области (МФЦ) или на официальном сайте mfc.ulgov.ru;
- посредством сайта Росреестра http://rosrestr.ru, воспользовавшись электронным сервисом «Получение сведений из ЕГРП».

Подготовка документа через МФЦ и Кадастровую палату занимает 5 рабочих дней.

Кто может запросить сведения из ЕГРП?

Это зависит от сведений, которые вы хотите получить. Например, запросить информацию о том, кто является собственником того или иного объекта недвижимости может любой человек. Это информация общего доступа, которая не содержит никаких персональных данных, кроме фамилии владельца. Более расширенную выписку с конкретной информацией о правообладателях может получить только сам собственник или его представитель по доверенности.

Также, хотелось бы успокоить граждан в части того, что не нужно обменивать раннее выданные свидетельства на выписку. Законом предусмотрено, что государственные органы, органы местного самоуправления, суды, а также иные органы и организации обязаны принимать для подтверждения регистрации прав на недвижимое имущество выписку из ЕГРП наравне со государственной регистрации права.

Подытожив, всю информацию о выписке, можно отметить, что в целом в работе ни юристов, ни риэлторов, ни в действиях граждан при сделках с недвижимостью от изменения формы документа, удостоверяющего право собственности, ничего не изменилось.

Информация предоставлена Филиалом ФГБУ «ФКП Росреестра» по Ульяновской области.

МӘКТӘП ТОРМЫШЫ

ӘБИЛӘР - ӘБЕКӘЙЛӘР

Әниемнең әнисе миңа әбекәй була. Мин аны бик яратам. Менә шундый җылы сүзләр белән күңелләрне эретте балалар, Әниләр көненә багышланган бәйрәмдә. Иске Кулаткы беренче номерлы урта мәктәбенең 3 А сыйныф укучыларының җитәкчеләре Х.Б. Усманова.

- Мин бүгенге көндә бик бәхетле онык. Ике әбиемнең дә күңел җылысын тоеп яшим. Туган авылыңда әбиләреңнең исән-сау булуы, бәхет түгел мени? Аларның очрашкач, бергә гөрләшеп сөйләшүләрен, юк-бардан да кызык табып көлүләрен карап торуы бик күңелле.Миңа аларның икесе дә бик кадерле.

Менә шулай шатланып – шатланып балалар чыгышлар ясадылар. Дәрестәндә балаларның әбиләре булу аларда йомшаклык, җылылык хисләре уята. Шуңа да бу бәйрәм бик җылы атмосферада үтте. Кунакка килгән әбекәйләр оныкларына карап, сөенеп тордылар, ә балалар бар осталыкларын күрсәтергә тырыштылар. Укытучы апалары Халидә Бариевна бик акыллы, тирән фикерле кеше. Балаларда өлкән буынга ихтирам тәрбияли.

Кунакларны уртага чакырып оныкларыннан әбиләре турында сөйләттерде. Шөкер, алар һәркайсы әбиләренең дә хәтта аларның әтиләренең дә исемнәрен дә беләләр. Бергәләп җырлау, бию, күңел ачу да кызык булды.

Соңыннан әбиләре пешергән тәмле күчтәнәчләр белән бергәләшеп чәйләр эчтеләр, фоторәсемгә төштеләр. Бу бәйрәм чәйләре араларны тагын да ныгытты. Тәҗрибәле укытучы, ана һәм әбекәй буларак Халидә Бариевнага шундый күркәм чара оештырган өчен олы рәхмәтләрен җиткерделәр.

Майзә МАСИЕВА.

ОЧРАШУ ФАЙДАЛЫ БУЛДЫ

Мәктәпнең соңгы сыйныф укучылары булачак һөнәрләре турында алдан ук күз алласын, әзерләнсен өчен өлкә мәгариф министрлыгы мәктәпләр белән берлектә төрле уку йортларында очрашулар оештыра. Күптән түгел генә Ульяновск шәһәренең Ленин мемориалында Ульяновский дәүләт университеты ачык ишекләр көне уздырды. Район администрациясе анда баруны әйбәт шартларда оештырды. Балалар яңа “Форт – транзит” автомашинасында барып кайттылар. Университет коллективы да яхшы әзерлек күрсәтте, балаларга кызыклы материаллар әзерләнгән иде. “Университетның казанышлары - синең өчен” дип исемләнгән видеороликта университет турында бик күп мәгълүмат тупланган иде. Укучыларны университетның ректоры үзе дә сәламләде, аларның сорауларына җаваплар бирде. Мемориалның зур залында үткән бу чарада концерт та күрсәтелде.

Кабул итү комиссиясе балаларга аңлату эшләре алып барды. Ленин мемориалының өченче катында Ульяновск дәүләт университетының барлык факультетлары турында бай һәм эчтәлекле материаллар тәкъдим ителде. XI сыйныф укучылары мондый очрашудан бик канәгать калдылар, үзләрен кызыксындырган барлык сорауларга да җаваплар алдылар.

Рәхимә ҮМӘРОВА,
Иске Кулаткы беренче номерлы урта мәктәбенең XI Б сыйныф җитәкчесе.

Мәгълүм булганча, ил Башлыгы В.В. Путин Указы нигезендә 2016 ел Россиядә Кино елы дип игълан ителде. Аның төп максаты - халык арасында киноны популярлаштыру, аның халыкара аренадагы урынын нык ныгыту, кино җитештерүне арттыру, киностудияләрне яңарту, төбәкләрдә кино күрсәтүне үстерү.

Кино - сәнгатьнең иң әһәмиятле төрләренең берсе. Ул җәмәгатьтә зур роль уйный. Милләтнең һәм халыкның имиджын формалаштыруда киноның мөһимлеге әйтеп бетергесез. Кино - кешенең психологик чарасы, ул уйландыра, тәрбияли, үзгәртә, ильамландыра. Күп кенә фильмнар кешенең күңелендә җылы хисләр калдыра, мәрхәмәт, хөрмәт, намус кебек кыймметләрне ассы-зыклый. Яшь буынга патриотик, рухи тәрбия бүрүдә дә аның йогынтысы зур. Хакимият тарафыннан да кинога зур игътибар бирелә. Чөнки ул сәясәтнең дәвамчысы буларак, иҗтимагый әһәмиятлелекне арттыра һәм популярлаштыра.

Илебездә беренче киносеанс 1896 елның 4 (16) маенда Петербургта үткән. Ә инде 1908 елның 2 (15) октябрьдә "Понизовая вольница" исемлесигез минутлык кино күрсәтелгән. Россиядә беренче төсле фильм экраннарга 1925 елда чыккан.

Кино елы кысаларында регионыбызда ел дәвамында төрле чаралар үтте. "Академия проекты" уңышлы гына эшли, туп хоккее буенча Дөнья Чемпионаты кысаларында "Чит ил киносы" баш астында Халыкара кинофестиваль үтте. "ВолгаКино" компаниясе ульянлылар катнашында «Хыял уйлану» тулы метражлы комедияле мелодрама төшерде. Халык культурасы үзәгендә яшьләр кино-мәктәбе эшли, беренче тапкыр экологик киноларга багышланган "Мәхәббәт планетасы" исемле Халыкара яшьләр фестивале оештырылды, "Кинолар төне" акциясе дә ульянлыларны битараф калдырмады. Музейларда Кино елына багышланган күргәзмәләр дә халык игътибарын яулый. В. Леонтьева исемендәге "Ихлас күңелдән" баш астында гаилә белән карый торган VIII Халыкара кино-телепрограмма фестивале өлкәдә югары дәрәҗәдә үтеп, күп санлы атаклы кино артистларны һәм кино яратучыларны берләштерде. Россия киносы көнен билгеләү уңаеннан барлык муниципаль берәмлекләрдә дә үз илебездә төшерелгән фильмнар күрсәтелде. Регионда балалар киностудияләре барлыкка килү дә - кинематографияне үстерүгә, яшьләрне җәлеп итүгә мөмкинлек ача. Шулай ук Кино елы кысаларында төрле районнарда яңа кинозаллар да ачылды.

Патриотизм һәм сугыш темаларына багышланган "Легенда №7", "Сталинград", "Батальон", "Битва за Севастополь» фильмнары ульянлыларның мәхәббәтен яулады һәм кинопрокатта уңышка ирешә. Әлеге чараларның төп максаты – Россиядә төшерелгән фильмнарны илдә һәм дөньяда таныту.

Безнең районда да Кино елы кысаларында күп төрле чаралар оештырылды. Мәктәп укучылары, балалар бакчалары нәниләре игътибарына төрле темаларны ачыклаучы мультфильмнар һәм фильмнар күрсәтелә. VII Бөтенроссия авыл Сабан туенда кунакларга "Киномобиль» мәйданында Николай Карамзинга багышланган һәм шулай ук татарча кинофильмнар тәкъдим ителде. Район мәктәпләрендә Кино елы кысаларында сыйныфтан тыш чаралар, күргәзмәләр үтте.Төрле оешма коллективлары өчен район мәдәният йортында элеккеге фильмнар күрсәтелде.

Киләчәктә кино сәнгатенә игътибар тагын да артсын, тамашачылар саны кимемәсен иде.

Әлфия ЯФАРОВА.

КҮҢЕЛЛЕ БӘЙРӘМДӘ

Ана сиңа гел яхшылык тели,
Гаепләрең булса кичерә.
Тугрылыклы калыйк гомер буе
Ана дигән күркәм кешегә.

25 ноябрь көнне Югары Терешка авылында, мәктәпнең актлар залында, Әниләр көненә багышланган кичә узды. Бу чараны әзерләүдә мәктәп директоры Гөлсиня Сафовна Алмакаева, укытучылар Иркя Загидулловна Абдулмәнова, Руфия Фәйзулловна Сафарова, мәдәният хезмәткәрләре Гөлнара Шәүкәтовна Мустафина, Рәшидә Абдулловна Биккинеева үзләренең көчләрен куйдылар. Кичәдә авылның барча әниләре кунак булдылар. Мәктәбебездә 6 гына укучы булуга карамастан, күмәкләшеп, мәктәп укытучылары һәм мәдәният хезмәткәрләре белән зур концерт оештырылган иде. Бәйрәм телевизион тапшыру формасында алып барылды, режиссер Иркә Абдулмәнова иде.

Форсаттан файдаланып, 2016 ел Сәламәтлекне саклау елы буларак, авылыбызның озак еллар сәламәтлек тармагында озак еллар хезмәт итүчеләрне хөрмәтләп, Рәхмәт хатлары белән бүләкләдек. Кичә чәй табыны артында дәвам итте, әниләребез матур җырларын җырладылар, шигырьләр сөйләделәр. Кичә бик күңелле узды. Барлык авыл халкы исеменнән әлеге бәйрәмне оештыручыларга зур рәхмәтемне белдерәсем килә. Киләчәктә дә шулай бергәләшеп, очрашып яшәргә Ходай Тәгаләбез язсын иде.

Югары Терешка авылы халкы исеменнән Нурҗиһан ЗАИТОВА.

ӘНИЛӘР, СЕЗ ЯШӘҮ ЧЫГАНАГЫ

Үткән атнада "Парус Надежды" инвалидларны реабилитацияләү үзәгендә Әниләр көненә багышланган бәйрәм кичәсе үткәрелде. Балалар үз куллары белән ясаган әйберләрдән зур күргәзмә ясадылар. Әниләре аларның кул эшләренә соклануып туя алмадылар. Зур залда чакырылган кунаклар өчен матур концерт программасы тәкъдим ителде. Балалар әниләренә карата булган мәхәббәтләрен, җылы, ягымлы шигъри юллар, моңлы җырлары аша җиткерделәр. Ә инде үзәктә хезмәт итүче педагоглар тарафыннан хәзерләнгән мавыктыргыч конкурсларда катнашып, бергәләп кызыклы күнегүләр эшләделәр һәм күңел ачтылар. Бәйрәм хөрмәтле әниләребезнең күңелләрендә җылы тәэсирләр калдырды.

Фирүзә Бимеева, "Парус Надежды" инвалидларны реабилитацияләү үзәге белгече.

БӘЙРӘМ КАЙТАВАЗЫ

АРАЛАРНЫ ЯКЫНАЙТЫП

23 ноябрь көнне Бахтеевка авылы мәдәният йортында Әниләр көненә багышланган бәйрәм чарасы үткәрелде. Әлеге кичә Иске Кулаткы пенсия фонды идарәсенең матди ярдәме һәм районыбызның пенсионерлар Союзы рәисе Р. Я. Мусинаның инициативасы белән оештырылды. Бәйрәмдә В. А. Ермолаева җитәкчелегендә Зирекле һәм Яңа Лебежайка авылларының "Мирас" фольклор төркеме катнашты. Чуваш Кулаткы һәм Бахтеевка авылы халкы аларның чыгышларын бик җылы кабул иттеләр. Аеруча өч телдә дә башкарылган җырлары белән тамашачыларның күңелләрен яулап алдылар. Тамашачылар игътибарына Иске Зеленай урта мәктәбе укытучысы Р. К. Абәйдуллина, авыл администраторы Х. Б. Касыймова һәм В. А. Ермолаева башкаруында мавыктыргыч сәхнә күренеше тәкъдим ителде. Т. А. Осипова сәнгатьле итеп "Бәхет" шигырен укыды. Ә инде Бахтеевка һәм Чуваш Кулаткы авылы халкы үзләренең матур чыгышлары белән җавап кайтардылар. Әниле - уллы Зөлфия Нәүмәтуллина һәм Габдулла башкаруында яңгыраган "Минем кечкенә улым" җыры барчабызның күңелләрендә җылы тәэсирләр генә калдырды. Бәйрәм сый-хөрмәт тулы чәй өстәлләре артында дәвам итте. Район пенсионерлар Союзы рәисе Р. Я. Мусина әниләр адресына җылы теләкләрен җиткерде. Бәйрәмдә катнашучылар өлкән буын турында даими кайгыртучанлык күрсәтеп яшәүче Пенсия фонды идарәсе начальнигы Ш. С. Курамшинга олы рәхмәт сүзләрен юлладылар. Пенсионерларыбыз киләчәктә дә яшь буынга дөрес тәрбия биреп үстерүдә бергә булыйк һәм шундый күркәм очрашуларыбыз дәвам итсен иде дигән теләктә калдылар.

Галина ИЛЬГАЧЕВА.

ӘНИЛӘРНЕ ОЛЫЛАП

Ноябрь ахырында без иң күңелле, иң җылы бәйрәмнәрнең берсен – Әниләр көнен билгеләдек. Бәйрәм уңаеннан Иске Кулаткы үзәкләштерелгән балалар китапханәсендә дә "Әниләр планетасы" исемле тематик кичә оештырылды. Аны әзерләүдә китапханәче Г.Х. Бекирова зур тырышлык куйды. Чарада Иске Кулаткы беренче номерлы урта мәктәбенең II "А" һәм II "Б" сыйныф укучылары үзләренең класс җитәкчеләре белән катнашты.

Кичә әниләр турында матур шигъри юллар белән башланды. Әйе, әни һәрбер кеше өчен дә иң кадерлесе, иң матуры, иң яхшысы, гомумән, тормышта иңиң әһәмиятлесе. Бала өчен җир йөзендә әнидән дә якты, әнидән дә рәхимле, әнидән дә олы җанлы зат юктыр. Алар дөньяның рәхәтен, күңелнең сафлыгын, пакьлеген аңларга өйрәтүчеләр. Шуңа күрә кичә дәвамында балалар сөекле әниләре турында эчтәлекле сөйләп, аларга булган мәхәббәтләрен белдерделәр.

Кече яшьтән ук әнинең дәрәҗәсен аңларга, аларны хөрмәтләп яшәргә, ярдәмчеләре, терәкләре булырга, беркайчан да онытмаска икәнлеген аңладылар. Балалар зур теләк белән төрле конкурсларда да катнаштылар. Әлеге кичә мәктәп укучыларының күңелендә якты хисләр булып мәңгегә сакланыр.

Әлфия АЛТЫНБАЕВА, Район үзәкләштерелгән китапханә методисты.

Президент подписал закон о снижении на 30% госпошлины на услуги, заказанные на порталах госуслуг.

Закон «О внесении изменения в статью 333-35 части второй Налогового кодекса Российской Федерации (в части уточнения порядка предоставления льготы по уплате государственной пошлины)» Документ предусматривает применение коэффициента 0,7 для расчёта размера пошлины за электронные госуслуги, заказанные и оплаченные на едином портале госуслуг (ЕПГУ) или региональных порталах, а также на иных порталах, интегрированных с единой системой идентификации и аутентификации (ЕСИА).

«Размеры государственной пошлины… за совершение юридически значимых действий в отношении физических лиц, применяются с учётом коэффициента 0,7 в случае подачи заявления о совершении указанных юридически значимых действий и уплаты соответствующей государственной пошлины с использованием единого портала государственных и муниципальных услуг, региональных порталов государственных и муниципальных услуг и иных порталов, интегрированных с единой системой идентификации и аутентификации», - говорится в тексте закона.

Это значит, что граждане, получившие услугу через портал госуслуг (при условии оплаты пошлины через портал), будут оплачивать госпошлину за нее по льготному тарифу с коэффициентом 0,7 - даже если результаты этих услуг выдаются в физической форме: оформление загранпаспорта, паспорта гражданина РФ, регистрация транспортного средства, свидетельство о заключении брака и пр.

Зарегистрироваться на Портале Госуслуг и подтвердить свою учетную запись можно в администрации района, на 2 этаже, кабинет № 219, телефон для справок: 2 -15 - 46.

ТӨНГЕ РЕЙДТА

2 декабрьдә, төнлә, Рәсәй эчке эшләр министрлыгының «Павловка» районара ГИБДД бүлеге хезмәткәрләре Иске Кулаткы районында «Аек түгел машина йөртүче» дигән операция үткәрделәр. Алар белән шулай ук «Күмәк көч» һәм «Яңа Дулкын» район телевидениесенең журналистлары, район администрациясенең «Ирекле дружина» әгъзалары катнаштылар.

Әлеге рейд төне буе дәвам итте һәм аның барышында 46 машина йөртүче туктатылды. Нәтиҗәдә, исерек килеш бер генә дә машина белән идарә итүче ачыкланмады.

ГИБДД хезмәткәкләре киләчәктә дә шундый рейдларны еш кына оештырырга булдылар, чөнки юлларда автомобильләрнең саны күпкә артты. Иске Кулаткы районында гына 4 меңгә якын төрле маркалы автомобиль бар. Шуңа күрә юл хәрәкәте машина йөртүчеләрдән дә, җәяүлеләрдән дә зур игътибар таләп итә.

Руслан ЮСУПОВ,
Юл хәрәкәте куркынычсызлыгын пропагандалау инспекторы,
өлкән лейтенант.

СӘЛАМӘТЛЕК – ИҢ ЗУР БАЙЛЫК

Сәламәтлек - кеше бәхетенең нигезе. Кеше исән булганда гына, үзенең теләк-омтылышларына ирешә ала, тормышны яратып яши. Һәр кеше озак һәм бәхетле яшәргә теләсә, иң беренче үзенең сәламәтлеге турында кайгыртырга тиеш. Ә инде балаларыбызның сәламәтлеге һәрвакыт игътибар үзәгендә булып, мөһим мәсьәлә итеп санала.

Үткән атнада "Чишмә" балалар бакчасында "ФГОС стандартлары кысаларында мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сәламәтлеген саклау" баш астында тәрбиячеләр катнашында район семинары оештырылды.

Бакча мәдире Г.И. Аблязова семинарны ачып, аның узу тәртибе белән таныштырды. Балаларның сәламәт булуы, аларны ныгыту, сәламәт яшәү рәвеше кагыйдәләре белән таныштыру, спортка мәхәббәт тәрбияләү турында сүз алып барды.

Чара дәвамында тәрбиячеләр: Л.Ш. Хабибуллина, Г.З. Кадермәтова, Н.Х. Азизова, М.Ш. Нәүмәтуллина балалар белән зарядка ясадылар, гимнастика күрсәттеләр, төрле физик күнегүләр башкардылар, хәрәкәтле уеннардан уйнадылар, гимнастика элементлары белән бию тәкъдим иттеләр. Нәниләрнең актив катнашулары, сәламәт булулары, яхшы физик әзерлекләре тәрбиячеләрнең үз эшләрен яратып башкарулары, балаларга нык тәрбия бирүгә омтылулары, бай тәҗрибәләре турында сөйли.

Кунаклар да чарада тик тормадылар. Алар бергәләп, дәртле музыкага флешмоб биеп, сәламәтлекләрен ныгыттылар.

Т.Т. Азизова һәм А.Р. Ханбикова кунакларга үз кулың белән физкультура җиһазлары ясау буенча мастер-класс күрсәттеләр.

Чара азагында семинарга нәтиҗә ясалды. Кунаклар тәрбиячеләрнең эшенә югары бәя биреп, әлеге коллективка эшләрендә уңышлар теләделәр. Үзара әңгәмә корып, тәҗрибәләре белән уртаклаштылар.

Чыннан да, дөньяда иң кирәк нәрсә – сәламәтлек. Һәр гаиләдә сәламәт яшәү рәвеше алып бару - мөһим. Балаларыбызны чыныктыру, дөрес тукландыру, бергәләп физик күнегүләр башкару, шәхси гигиена кагыйдәләрен өйрәтү, саф һавада йөртү – һәркемнең хәленнән килә торган эшләр. Авырмагыз, сәламәтлегегез турында кайгыртып яшәгез! Исәнсау булыгыз!

Ә. ЯФАРОВА.

ӘНИЛӘР ХӘРМӘТЛӘНДЕ

Әни… Дөньяда иң кадерле, иң якын, иң сөйкемле кеше ул! Әни… Аның күзләре шундый ягымлы һәм мөлаем, әйтерсең, бөтен дөньяның сабырлыгын, акылын, төрле төсләрдәге матурлыгын, гүзәллеген җыйган диңгез! Ә әнкәйнең куллары иң-иң җылы, иң-иң кадерле куллардыр, мөгаен. Шул ягымлы куллар сиңа кагылуга, бөтен кайгыларың югала, "Балам!" дип аркаңнан сыйпаса, сиңа гүя канатлар үсә…

Әниләр көне уңаеннан Иске Атлаш урта мәктәбендә дә ата-аналар җыены үткәрелде. Әлеге җыенда мәктәпнең барлык укучылары да актив катнашты. Авылыбыз имамы Нурали абый Сафаров, "Иске Атлаш авыл поселениесе" Башлыгы Н. Р. Чамкаева һәм мәктәп директоры Н. Л. Ямашева чакырылган кунакларга матур бәйрәм котлауларын юлладылар. Шулай ук бик күп әниләрне борчыган начар гадәтләрдән саклану мәсьәләләренә дә тукталдылар. Мәктәпкәчә төркем балалары әниләренә багышлап матур җырлар башкардылар, шигырьләр укыдылар һәм биеделәр. Концерт программасын алып баручылар мәктәп укытучысы Р. Ф. Сәйфетдинова һәм XI сыйныф укучысы Луиза Калюшева йөрәккә үтеп керерлек матур шигъри юллар юлладылар. Ә инде укучыларның үз куллары белән ясаган бүләкләре әниләрне тагын да шатландырды. Бәйрәм барчабызның күңелләрендә дә җылы тәэсирләр калдырды.

З.Р. ХАМЗИНА,
ата – аналар комитеты рәисе.

ЭТО ВАЖНО!

ПОРЯДОК ПРЕДСТАВЛЕНИЯ ОТЧЕТНОСТИ И УПЛАТЫ СТРАХОВЫХ ВЗНОСОВ В 2017 ГОДУ

С 1 января 2017 года администрирование страховых взносов на обязательное пенсионное и обязательное медицинское страхование будет осуществлять Федеральная налоговая служба Российской Федерации*.

ПЕНСИОННЫЙ ФОНД РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ БУДЕТ ПРОДОЛЖАТЬ АДМИНИСТРИРОВАНИЕ:

- страховых взносов, уплачиваемых лицами, вступившими в правоотношения по обязательному пенсионному страхованию;
- дополнительных страховых взносов на накопительную пенсию.

ПЕНСИОННЫЙ ФОНД РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ ПРОДОЛЖИТ ПРИЕМ:

- сведений индивидуального персонифицированного учета по форме СЗВ-М (не позднее 15-го числа месяца, следующего за отчетным);
- сведений о стаже застрахованных лиц (ежегодно, не позже 1 марта следующего года)**;
- реестров застрахованных лиц, за которых перечислены дополнительные страховые взносы на накопительную пенсию и уплачены взносы работодателя (не позднее 20 дней со дня окончания квартала);
- копий платежных документов от застрахованных лиц об уплаченных дополнительных страховых взносах на накопительную пенсию за истекший квартал (не позднее 20 дней со дня окончания квартала).

ПФР ПРОДОЛЖИТ ОСУЩЕСТВЛЯТЬ КОНТРОЛЬНЫЕ МЕРОПРИЯТИЯ ПО ПЕРИОДАМ, ИСТЕКШИМ ДО 1 ЯНВАРЯ 2017 ГОДА, В ЧАСТИ:

- приема отчетности по РСВ-1 за 2016 год (в срок до 15 февраля 2017 года в бумажном виде и до 20 февраля 2017 года в электронном виде);
- приема и обработки других расчетов (уточненных расчетов) по страховым взносам;
- проведения камеральных и выездных проверок и вынесения решений о привлечении (об отказе в привлечении) по результатам камеральных и выездных проверок;

а также:

- принятия решений о возврате излишне уплаченных (излишне взысканных) страховых взносов;
- списания невозможных к взысканию сумм недоимки по страховым взносам, пеней и штрафов.

** В соответствии с федеральным законом от 03.07.2016 № 243-ФЗ и федеральным законом от 03.07.2016 № 250-ФЗ.*

*** До 1 января 2017 года эти данные включены в отчет РСВ-1, которые работодатели подают раз в квартал*

www.pfrf.ru

ИХТИРАМГА ЛАЕК ШӘХЕС

ХЕЗМӘТ БИЗИ АНЫҢ ЕЛЛАРЫН



Иске Кулаткы эшчеләр поселогында гомер итүче Адельша Исмәгыйлович Абдюшевның исеме районыбызда күп кешегә таныш. Чөнки ул җаваплы урыннарда хезмәт итеп, кешеләр белән яхшы мөнәсәбәттә булып, хәленнән килгән кадәр аларга ярдәм итеп яшәде. Аның эшкә уңганлыгы, пөхтәлеге турында сөйләп торасы да юк. Шундый уңай сыйфатларга хас булып сизелми дә еллар үтеп киткән. 9 декабрьдә Адельша Исмәгыйлович үзенең 80 яшьлек олы юбилеен билгеләп үтә. Шушы уңайдан алдагы материалда сүз аның турында барачак.

- Хезмәт белән мәшгуль булып, гомер елларым бик тиз үтеп китте һәм олы яшькә җиткәнемне сизми дә калдым, - дип сүзен башлады Адельша Исмәгыйлович «Күмәк көч» район газетасы журналистлары белән очрашуда.

- Вакытны туктатып булмый, бүген 80 яшькә җитүемне зур шатлык белән каршылыйм. Ник дисәгез? Ходай Тәгалә миңа шушы көнгә кадәр саф һаваны сулап, күзләрем белән якты дөньяны күреп, аңа сокланып, кешеләр белән аралашып яшәргә насыйп иткән. «Минем еллар - минем байлык!», - дип тикмәгә генә җырларда җырламыйлар бит.

Һәм дөрестән дә шулай. Адельша Исмәгыйлович бүген яшәгән еллары, дөньяга дөрес карашы, башкарган изге гамәлләре белән рухи яктан иң бай кеше. Ул моның турында бихисап якын кешеләре, дуслары белән рәхәтләнеп уртаклаша ала.

Бөек Ватан сугышы еллары да аның бала чагына, күңеленә тирән яралар салган. Бәлки, яшь вакытта күргән авыр михнәтләр тормышның кадерен белергә, төрле киртәләрне буйсындырырга, хезмәтне сөяргә өйрәткән дә.

Менә шулай тормыш мәшәкатьләренә күмелеп, безнең язма героебызның сизелми дә бала чагы, мәктәп еллары үтеп китә. Иске Кулаткы урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, үзенә һөнәр үзләштерү максаты белән Вольск шәһәренең профтехучилищесына укырга керә. Тракторчы-экскаваторчы һөнәрен үзләштергәннән соң, яшь егет Саратов индустриаль техникумын тәмамлый. Кулына диплом алгач, аны Вольск шәһәренә үзе белем алган профтехучилищега укытучы итеп юнәлдерәләр. Ул биредә 3 ел курсантларга техник профессиясе буенча белем бирә.

- Чит җирләрдә яшәсәм дә, Иске Кулаткымны беркайчан да онытмадым. Туган төбәккә мәхәббәт өстенлек алды – туган авылыма әйләнеп кайттым, - дип сүзен дәвам итә Адельша Исмәгыйлович. - Үземне «Сельхозтехника» берләшмәсенә сәүдә буенча инженер итеп эшкә алдылар. Аннан соң 3 ел дәвамында Иске Кулаткыда функцияләгән 7 нче номерлы Новоспасск профтехучилищесы филиалында курсантларга белем бирдем. Билгеле, туган төбәктә хезмәт итү, халык белән аралашу - күңелгә якын иде.

Озак та үтми Адельша Исмәгыйловичның техник яктан грамоталы, оештыру эшләрен сәләтле алып баруын сизеп, район җитәкчеләре Иске Кулаткы район авыл хуҗалыгы идарәсенә инженер итеп күчүен соралалар. Ул моңа каршы килмичә, әлеге вазифаны җаваплылык белән башкара. Биредә хезмәт иткән чорда бай тәҗрибә туплаган белгеч «Күмәк көч» район газетасы белән нык элемтәгә кереп, авыл хуҗалыгы тормышын яктыртып, газета битләренә эчтәлекле материаллар яза.

- Бәлки, шуңа ул вакытта газетаның баш редакторы Әнвәр Закирович Мухаметрахимов белән безнең элемтәләребез якынайды. Ике ел инженер булып эшләгәч, ул мине редакциянең хатлар бүлегенә журналист итеп эшкә күчерде, - дип искә ала үткәннәрне юбиляр. – Биредә ике ел хезмәт иткәч, язмыш мине район типографиясе белән тоташтырды һәм анда директор вазифаларын башкаруга керештем.

Адельша Исмәгыйлович әлеге оешмага калган хезмәт биографиясен багышлый һәм район типографиясендә 38 ел дәвамында директор вазифасын башкара. Шушы чорда аның уңышлары турында сөйләп тә, язып та бетергесез. Ул җитәкчелек иткән чорда аның кул астында 13 кеше хезмәт итте. Элеккеге елларда, билгеле, типографиядә камилләштерелгән җиһазлар һәм компьютерлар да юк иде, шуңа күрә, күпчелек эшләр кул белән башкарылды. Әлеге оешмада хәреф кою, кәгазь кисү, төрле заказларны бастыру, аларны беркетү өчен тимер чыбыктан юләү станоклары (барлыгы 7 төр) эшләп тордылар. Коллективны җитәкчелек итү белән бергә Адельша Исмәгыйлович аларның һәрвакыт төзек булуын да тәэмин итте.

- Кулына тимер тотса, аңа җан кертә, - дип сөйли иде дуслары бу җитәкче турында. Дөрестән дә шулай, чөнки югарыда санап киткән машиналарга запас частьләрне авылдан табып булмый, ә шәһәргә бару - читен иде. Шуңа күрә, тәҗрибәле җитәкче кулына тимер тотып, төрле инструментлар кулланып, аларны ансат кына ясап, машиналарның өзлексез эшләвен тәэмин итте. Аның осталыгы, оперативлыгы нәтиҗәсендә «Күмәк көч» район газетасы һәм башка заказлар вакытында басылалар.

Ул елларда электр утлары да еш кына сүнә иде һәм тәҗрибәле белгеч запас фидер булдырып, типографияне өзлексез эшләтә белде. Аның тырышлыгы белән бу коллективта эшчеләр эргәдәш (смежные) һөнәрләр үзләштерделәр һәм барысы да барлык машиналарның артына утырып эшли алдылар.

Адельша Исмәгыйлович район типографиясе белән идарә иткән чорда коллектив - матбугат министрлыгының байрагын, ә үзе күптөрле Почет грамоталарын алуга ирешә. Билгеле, бу казанышлары аңа Федераль дәрәҗәдә «Хезмәт ветераны» исемен йөртүгә лаеклы ясады.

Коллектив турында кайгырткан җитәкчене эшчеләре дә ихтирам иттеләр. Чөнки ул аларның көндәлек тормышларында булган проблемаларны да гел уңай якка чишеп килде.

Рәсемдә: Ульяновск мәдәният профсоюзлары комитетының рәисе Бузаев типография директоры А. И. Абдюшевка күчмә Кызыл Байрак тапшыра. 1980 ел.

Лаеклы ялга чыккач та, Адельша Исмәгыйлович әлеге оешмада 10 ел хезмәт итте, чөнки аны югарыдагы җитәкчеләр шулай кирәк дип санадылар һәм олы яшенә җитсә дә, ул үз эшен күңелен биреп башкарды.

Адельша Исмәгыйлович күп шөгыльгә ия дип әйтсәк, һич ялгыш булмас. Хезмәт ветераны лаеклы ялга чыксa да, тик тормый. Сәнгатьне якын итеп, дистә елдан артык районыбызның мәдәни тормышына күмелеп яши. Талантлы җыр остасы буларак, ул Хәсән Туфан иҗатындагы җырларны үз итә, «Чишмә» ветераннар хорында актив катнаша , ә инде җитез биюче буларак, район сәхнәсендә тамашачылар каршында да еш чыгышлар ясый. Ул район сәхнәсендә генә түгел, «Чишмә» ветераннар хоры белән хәтта Төмән, Свердловск өлкәләрендә, Кырым республикасында Бөтенроссия «Түгәрәк уен” фольклор фестивальләрендә катнашып, зур уңышларга ирешә.

Шәхси тормышында да Адельша Исмәгыйлович башкаларга үрнәк. Ул тормыш иптәшен Тәүхидә Хөсәеновнаны тирән ихтирам итә. Алар бергә 38 ел тату яшиләр. Заманында бу гаилә йорт тулы мал-туар, кош-корт, хәтта икешәр сыер да асрадылар.

Адельша Исмәгыйлович үзе яшәгән урамны төзекләндерүне дә игътибар үзәгендә тота. Моның турында аның матур итеп бизәлгән өе, чиста итеп җыештырылган капка алды ачыктан-ачык сөйли.

Менә шулай матурлыкка сокланып, халыкка файда күрсәтеп, кешеләрне шатландырып, безнең юбилярыбыз, коллегабыз олы бәйрәменә килеп җиткәнен дә сизми калган. Шушы уңайдан без дә аның шатлыклы тойгыларын уртаклашабыз һәм ихлас күңелдән: «Юбилеегыз котлы булсын Адельша Исмәгыйлович! Киләчәктә исәнлектә-саулыкта яшәргә гомер бирсен үзегезгә!», дигән якты теләкләр юллап калабыз.

Рәстәм АРИФУЛЛИН.

РӘХМӘТ ХАТЫ

ҮЗ ЭШЛӘРЕНЕҢ ОСТАЛАРЫ

Кеше олыгайган саен сәламәтлеге нык сиздерә башлый. Исәнлегебез какшау сәбәпле, безгә Иске Атлаш участок больницасында дәваланырга туры килде. Безне тиз арада аякка бастырдылар. Биредә эшләүче хезмәткәрләр һәрчак ачык йөзләләр, киң күңеллеләр, йомшак сүзләләр. Авыруларга карата шундый игътибарлы, эшләренә тугры булулары бары тик соклану хисе генә уята.

Безгә тиз арада диагнозны куеп, дәвалануны билгеләделәр. Иске Атлаш больницасының баш табибы Румия Алимовна Муллабаевага аерым рәхмәт сүзләре юллыйсы килә. Ул һәрвакыт авыруны игътибар белән тыңлап, файдалы киңәшләр бирә, өметсезлеккә бирешмәскә өнди. Эшен яратканга, хезмәтенә бөтен күңелен бирә ул.

Шәфкать туташлары Гүзәл Уразлина, Алия Бочкарева, Иркә Рафикова, Римма Сагатова бары тик мактау сүзләренә генә лаеклылар. Алар үз эшләрен зур җаваплылык һәм профессионализм белән башкаралар.

Шулай ук авыл больницасын саклап калганнары, авыл халкының проблемаларына битараф булмаганнары, авыл кешеләренең сәламәтлекләрен кайгыртып яшәүләре өчен район Башлыгы Эдуар Әнвәрович Ганеевка, Иске Кулаткы район больницасының баш табибы Сергей Александрович Кунеевскийга чын күңелдән олы рәхмәтләребезне белдерәбез.

Аларга барчасына да исәнлек-саулык, җан тынычлыгы, гаиләләре белән дус-тату, мул тормышта матур яшәүләрен телибез. Авыр эшләрендә уңышлар гына юлдаш булсын иде.

Дәваланучылар исеменнән Мөнҗия Давыдова, Мөнирә Сафарова, Разия Зурагаева.
Иске Атлаш авылы.

ТӘБРИКЛӘҮЛӘР КАБУЛ ИТЕГЕЗ!

Иске Кулаткы эшчеләр бистәсендә гомер кичерүче Адельша Исмәгыйлович АБДЮШЕВ 9 декабрьдә үзенең 80 яшьлек олы юбилеен каршы ала. Безнең өчен якын булган кадерле туганыбыз!

Без сине 80 яшьлек олы юбилеең белән чын күңелдән кайнар тәбрик итәбез! Сиңа исәнлек-саулык, җан тынычлыгы, ямьле көннәр, сөенечле иртәләр телибез, елмаерга сиңа һәр көн саен чыксын мең сәбәп, бәхет нуры балкып торсын өеңнең һәрбер почмагында! Картлык көннәрең бары тик шатлыкта гына үтсен, үз аягында йөреп узсын гомерең. Гел шулай сабыр холыклы, саф күңелле, ягымлы бул. Аллаһының мең рәхмәте яусын сиңа. Без сине чиксез хөрмәт итәбез һәм чын йөрәктән яратабыз.

Гади,сабыр, олы җанлы син,
Кылганнарың бары изгелек.
Кайгыларсыз үтсен һәрбер көнең,
Бәхетләрең булсын гомерлек.
Теләкләрнең кайсын теләсәк тә,
Аз булыр күк синең хөрмәткә.
Аяз булсын мәңге күңел күгең-
Без калабыз шушы теләктә.

Изге теләкләр белән якын туганың Кәрим Сәмирханов, кызы Амаль, уллары Камил һәм Нариман.

Иске Кулаткы - Калининград.

Безнең өчен якын булган хөрмәтле туганыбыз Адельша Исмәгыйлович АБДЮШЕВ!

Без сине олы юбилеең - 80 яшь тулу көнең белән чын күңелдән котлыйбыз! Алдагы гомереңдә кайгы-хәсрәт күрмичә, картаюны сизмичә, яшәү дәрте сүнмичә, шатлыкларга төренеп яшәвеңне телибез. Туар таңнарың өметле, киләчәк һәм бүгенге көнең тыныч, гомер юлың якты булсын.

Күпме генә бәхет теләсәк тә,
Бик аз булыр кебек сизелә.
Ярдәм кулы суздың кирәк чакта,
Шәфкатьле син һәрбер кешегә.
Шуңа сине гел дә яратабыз,
Дус-ишләрең йөри килгәләп.
Сау-сәламәт булып, туксанны да
Үткәрергә язсын бергәләп.

Изге теләкләр белән Фирдәүс Юсупова, уллары Искәндәр, Имран, килене Татьяна, оныгы Камил.

Иске Кулаткы - Сызран, Уфа.

Вязовый Гай авылында гомер итүче Бибиҗан Алихан кызы ИКСАНОВАГА 10 декабрьдә 70 яшь тула. Кадерлебез безнең!

Ихлас йөрәктән сине туган көнең – күркәм юбилеең белән тәбрик итәбез. Сиңа иман байлыгы, саулык-сәламәтлек, бәхетле картлык көннәре, матур киләчәк насыйп итсен. Алдагы көннәрдә дә күңел кояшыңны сүндермичә, якыннарыңа яшәү көче биреп, һәрвакыт көләч йөзле, шат күңелле булып, тормышыңның һәр мизгелен кабатланмас җыр итеп, бала-оныкларыңның бәхетен, уңышларын, матур тормышларын күреп яшәргә язсын.

Юбилеең белән котлап,
Зур бәхетләр сиңа телибез.
Үзең кешелекле булган өчен,
Олылыйбыз бүген сине без.
Иссен җилләр, узсын еллар,
Картаймасын тик йөрәк.
Озын-озак яшә әле
Бездән сиңа шул теләк.

Изге теләкләр юллап, каенсеңелләрең Сәйдә-Мәсум, Сәдәт-Рафаэль, Серур-Абдулхалим, каен- энеләрең Кыяметдин-Рушания, Исмаил-Гөлсем, Сәмәт-Сурия барчасы да бала-оныклары белән.

Вязовый Гай – Мосеевка – Зирекле – Яңа Кулаткы.

Хөрмәтле Адельша Исмәгыйлович АБДЮШЕВ!

«Күмәк көч» район газетасы Сезне 80 яшьлек олы юбилеегыз белән кайнар тәбрик итә. Киләчәк тормышыгыз нәрвакыт исәнлектә-саулыкта узсын. Ак бәхетләргә күмелгән тыныч картлык көннәре телибез. Элек елларда типографиядә «Күмәк көч» район газетасын бастыруда Сезнең хезмәт өлешегез чиксез. Карусыз хезмәтегез өчен олы рәхмәт Сезгә!

Сез бүген районыбызда зур абруй яулап, олы ихтирамга лаек булган кеше. Алдагы гомерегездә дә гел яхшылыклар һәм игелекләр теләп калабыз.

Котлы булсын юбилеегыз
Якты булсын күңелегез.
Гел шатлыкларга уралып,
Үтсен калган гомерегез.
Сезнең юллар гөрләп узды.
«Күмәк көч» белән бергә
Киләчәктә дә аралашып,
Без дус булыйк гомергә.

Иске Кулаткыда яшәүче, күптәнге дустыбыз Адельша Исмәгыйлович АБДЮШЕВКА 9 декабрьдә 80 яшь тула.

Без аның белән бик озак вакыт аралашып яшибез. Ул искиткеч тырыш кеше. Аның белмәгән эше юктыр, сыман. Бүгенге көндә дә ул үзенең эшләрен тиешле җиренә җиткереп, зур игътибарлык белән башкара. Ул эш башкарганда, мин аңа бик гаҗәпләнәм һәм исем китеп, сокланып карап торам. Безгә акыллы киңәшләрен биргән өчен аңа олы рәхмәтләр генә әйтәм. Адельша Исмәгыйлович тормыш иптәше Тәүхидә Хәсәеновна белән 38 ел бергә матур, тату тормышта яшиләр.

Хөрмәтлебез! Без Сезне чын күңелдән 80 яшьлек олы юбилеегыз белән тәбрик итәбез! Сезгә, дөньядагы булган барлык изге теләкләрне телибез. Исәнлек-саулык, тыныч-шат тормыш, бәхет, киләчәктә дә уңышларга ирешеп,Тәүхидә Хәсәеновна белән икегезгә дә озын, тигез гомер телибез.

Котлы булсын синең юбилеең,
Шатлык балкып торсын йөзеңдә.
Безнең өчен бик тә кадерле син,
Рәхмәт яусын барысы өчен дә.
Тән сихәте бирсен сиңа Ходай,
Кызганмасын синнән шатлыкны.
Иман нуры белән балкып торган,
Игелекле, тыныч картлыкны.

Иң изге теләкләр белән Роберт Ахметович, хатыны Галия Ярулловна, балалары Гөлнара Робертовна, Ленар Робертович Ягодиннар һәм өч оныклары.

Иске Кулаткы – Тольятти – Ульяновск - Мәскәү.

Хөрмәтле Флера Азимҗановна АМИРОВА!

Мәгариф хезмәткәрләренең район профсоюз оешмасы һәм Урта Терешка урта мәктәбе коллективы Сезне истәлекле – 55 яшьлек юбилеегыз уңаеннан кайнар тәбрик итә. Сезгә исәнлек-саулык, күңел тынычлыгы, шатлыклы көннәр, якыннарыгызның, туганнарыгызның ихтирамын һәм игътибарын тоеп яшәвегезне телиләр. Якты көннәр, аяз таңнар гына тормышыгызны бизәп торсын. Киләчәк көннәрегез өметле булсын, зур шатлыклар гына кәтсен Сезне. Карусыз хезмәтегез өчен олы рәхмәт Сезгә.

Гомерләрне еллар билгеләми,
Яшәү дәрте булсын күңелегездә.
Сәламәтлек, бәхет-куанычлар
Юлдаш булсын Сезгә гомергә.

Хөрмәтле Адельша Исмәгыйлович АБДЮШЕВ!

Шушындый зур һәм якты бәйрәмең белән көнендә без сиңа ихлас котлауларыбызны юллыйбыз.Сиңа гомернең иң озынын, бәхетнең иң зурысын, шатлыкларның иң олысын юллыйбыз. Якты ал таңнар, зәңгәр күкләр синең күңеленне һәрчак яктыртсын, балкытып торсын. Киләчәктә дә кардәш-туганнарыңның игелеген, ихтирамын, җан җылысын тоеп, сөенечләргә куанып яшәвеңне телибез.

Картлык сезне җиңә алмый,
Иҗади сезнең күңел.
Тәбрик итәбез, телибез,
Җыр кебек матур гомер.
Картлык сүзен онытыйк әле,
Иҗат көч һәм дәрт бирә.
Дуслар – сокланып нәрвакыт
Тик карасыннар безгә!

Матур теләкләр белән “Чишмә” ветераннар хоры.

Урта Терешка авылында туып үскән, бүгенге көндә Новоспасск эшчеләр бистәсендә яшәүче Зәйтүнә Шәйдулловна АКСӘНОВАГА 10 декабрьдә 70 яшь тула. Кадерле тормыш иптәшем, сөекле әниебез, яраткан әбекәебез!

Әниебез олы йөрәкле, сабыр, ярдәмчел, киң күңелле, ачык йөзле, кеше. Безнең өчен үрнәк һәм бик зур терәк ул. Өебезнең – нуры, тормышыбызның – зур өлгесе, һәрберебезнең ныклы терәге булган кадерлебез безнең. Ихлас күңелдән сине әлеге матур юбилеең белән котлыйбыз. Син янәшәбездә булганда, күңелебез тыныч, тормышыбыз имин безнең. Яныбызда синдәй игелекле, сабыр, тәпле киңәшләре белән ярдәм итәрлек кешебез барында без чиксез бәхетле. Безгә биргән яхшы тәрбияң, акыллы киңәшләрең өчен бик зур рәхмәт сиңа, әни.

Сөйкемле карашың кояшка тиң,
Бар тормышны нурга күмәсең.
Бу дөньяның барлык хикмәтләрен
Бары тик син генә беләсең.
Тормышта гел ярдәм итеп тора
Зирәк киңәшләрең, җылы сүзең.
Иркәлисең, яратасың, юатасың,
Тыңлыйсың да, аңлыйсың да үзең.

Җылы теләкләр белән тормыш иптәшең Мәүлет Юсупович, кызың Флера, улың Марат, оныгың Флорид һәм барча туганнарың.

Новоспасск – Урта Терешка – Казан – Ташкент – Мәскәү.

Иске Мостяк авылында туып үскән, хәзерге вакытта Самара шәһәрендә яшәүче Кашаф улы Сәит ХӨСӘЕНОВКА – 60 яшь! Кадерлебез безнең!



Ихлас күңелдән сине гомер бәйрәмең белән котлыйбыз. Сиңа булган рәхмәтләребезне, күңелдәге теләкләрне сүз белән генә әйтеп бирергә мөмкин түгел, алар иксез-чиксез. Син безнең таяныч та, ышаныч та, яклаучыбыз да, саклаучыбыз да. Сиңа озын гомер, бәхет-шатлыклар, җан тынычлыгы, тән сихәтлеге телибез. Кайгы-хәсрәткә бирешмичә, һаман шулай көчле рухлы һәм ярдәмчел, изге күңелле булып кал. Балаларыңның игелеген күреп, озак яшәргә насыйп булсын. Рәхмәтләргә һәм рәхәтләргә төренеп яшә.

Юлдаш булып гомер
юлларыма,
Шатлык һәм кайгыны
уртаклашып,
Тормыш юлын үттек
җитәкләшеп.
Авыр чакларда һич
калмадык шашып,
Шатлансак, китмәдек
чиктән ашып.
Телибез сиңа изге
теләкләрне
Бүгенге бәйрәм йөзеннән.
Карап торсын яшьлек,
авыз ерып,
Матур үткән гомер
көзеннән.

Хатының Наилә Сәләйман кызы, балаларың, оныкларың.

Самара шәһәре.

Хөрмәтле Хания Сатдаровна ИСӘНОВА!

Иске Кулаткы район пенсионерлар Союзы Сезне күркәм юбилеегыз белән ихлас күңелдән тәбрик итә. Сезгә шушы бәйрәмегездә теләкләрнең иң изгесен, иң сафын юллыйбыз. Аллаһы Тәгалә алдагы көннәрегездә дә җан тынычлыгы белән исәнлектә-саулыкта, иминлектә, якыннарыгызның игътибарын, яратуын тоеп, бәхетле гомер кичерергә язсын. Иң зур бүләгебез – күңел җылыбыз, хөрмәтебез.

Олы җанлы, киң күңелле булуыгыз өчен
Рәхмәт ява Сезгә һәркайсыбыздан.
Сәламәтлек, тыныч, тигез тормыш –
Шул теләкләрне кабул итегез бездән.

ВЕТЕРАННАРНЫ КОТЛЫЙБЫЗ!

2016 елның декабрь аенда районыбызда гомер кичерүче **Бөек Ватан сугышының тыл хезмәтчәннәре Рәшидә Солтановна Хәкимова (Иске Зеленай), Фатиха Зарифовна Алимова (Иске Зеленай), Галина Ярулловна Руденко (Иске Кулаткы), Рәхимә Абдулахатовна Рәзәпова (Иске Кулаткы), Хания Сатдаровна Исәнова (Иске Кулаткы), Зөһрә Исламовна Ахмерова (Иске Кулаткы), Фәүзия Әхмәдиевна Хөсәинова (Яңа Зимница), Нәзирә Абдулкадировна Мохаммедова (Югары Терешка), Бибинур Атаулловна Аминова (Урта Терешка), Шәфика Сәләймановна Аббәсова (Иске Атлаш), Надия Шакировна Давыдова (Иске Атлаш), Рәйсә Мавлютовна Курмаева (Иске Атлаш), Таһир Закирович Давыдов (Иске Атлаш), Мәрзия Абубәкәровна Байбикова (Карамалы), Хәлимә Сәләймановна Назирова (Усть Кулаткы),** Бөек Ватан сугышы елларында туган балалар статусын йөртүче һәм декабрь аенда үзләренең олы юбилейларын билгеләп үтүче **Мияссәр Исхакович Абдрахманов (Бахтеевка), Адельша Исмәгыйлович Абдюшев (Иске Кулаткы), Сания Алимҗановна Абдюшева (Иске Кулаткы), Рәуф Яхъевич Абсатдаров (Иске Кулаткы), Галимә Шәйдулловна Азизова (Иске Мостяк), Рәшит Хөсәинович Әксәнов (Иске Кулаткы), Рәшит Сәитович Алиев (Яңа Терешка), Сания Салиховна Алюшева (Иске Кулаткы), Зәһидә Исхаковна Бикбаева (Иске Зеленай), Сәйдә Билаловна Кипчатова (Иске Кулаткы), Шәфика Шакировна Курмакаева (Иске Атлаш), Разия Сәләймановна Масаутова (Кирюшкино), Равза Исхаковна Мөрсәлимова (Вязовый Гай), Кәбир Батырханович Мохаммедов (Иске Кулаткы), Разыя Алимовна Насыйрова (Яңа Кулаткы), Валентина Семеновна Пайдулова (Чуваш Кулаткы), Зәйтүнә Исмәгыйловна Рамаева (Иске Зеленай), Рәшит Мөдәрисович Рәхмәтуллин (Иске Зеленай), Абдулаҗан Якубович Сәитов (Иске Кулаткы), Расимә Исхаковна Сәләева (Иске Кулаткы), Зәйтүнә Илачевна Сәләйманова (Усть Кулаткы), Сабира Шакировна Хәбибуллина (Иске Зеленай), Зиннәтулла Солтанович Хәкимов (Иске Зеленай), Иван Ильич Хурасев (Чуваш Кулаткы), Мөнир Закирович Шәмионовны (Урта Терешка)** район ветераннар Советы чын күңелдән олы бәйрәмнәре белән тәбрик итә. Дәһшәтле сугыш елларында дөньяга килеп, шатлыклы, борчу-хәсрәтсез, михнәтсез балачактан мәхрүм булдыгыз. Әмма сугыштан соңгы елларда илебезне торгызуда, халкыбыз, киләчәк буын рәхәт тормышта яшәсен өчен, гомер барышында күп тырыштыгыз, үзегездән өлеш керттегез. Сезгә саулык-сәламәтлек, гаилә бәхете, җан тынычлыгы телибез. Киләчәк тормышыгызда да саулыкта, муллыкта, якыннарыгызның игътибарын, җылысын тоеп яшәргә насыйп итсен.

Хөрмәтле юбилярлар!

Сезнең тормыш юлы – матур тарих,
Күпләр өчен үрнәк булырлык.
Рәхмәт, дибез, Сезгә чын йөрәктән
Сезнең гомер – безнең горурлык.

СПОРТ - СПОРТ - СПОРТ

ЯШЬ ТЕННИС ОСТАЛАРЫ ЯРЫШТЫ

Үткән атнада Иске Мостяк урта мәктәбендә Сәламәтлек саклау елына багышланган өстәл теннисы буенча XI традицион турнир үткәрелде. Спорт бәйрәме мәктәп укучыларының, “Мостяк” авыл поселениесе администрациясенең Башлыгы Ө. Ф. Резвановның, “Мостяк” авыл поселениесе Башлыгы, Иске Мостяк урта мәктәбе директоры М. М. Нугаевның, Иске Кулаткы район администрациясе Башлыгының социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, район мәгариф идарәсе начальнигы Ф. З. Зайнетдинованың чыгышлары белән башланды. Россия гимны астына тантаналы рәвештә флаг күтәрү церемониясе башкарылды. Спортчыларга Иске Кулаткы районы Башлыгы Э. Ә. Ганеев һәм Иске Кулаткы район администрациясе Башлыгының кеше потенциалын үстерү буенча беренче урынбасары В. А. Деникаева да котлау сүзләрен җиткерделәр һәм уңышлар теләделәр. Физкультура укытучысы Н. М. Фәтхуллин катнашучыларны ярышларның тәртибе белән таныштырды. Ярышлар берьюлы берничә өстәл артында башланып китте. Уенчылар әйтүенчә, көчле спортчылар белән ярышу җиңел түгел, әлбәттә, әмма мондый ярышларда алар осталыкларын үстерәләр, башка спортчылар белән тәҗрибә уртаклашалар. Барлык яшьтәге төркемнәр арасында да Кирюшкино авылы спортчылары беренчелекне яуладылар. Икенче урынга Иске Мостяк, механика-технология колледжы һәм өченче урынга Урта Терешка авылы поселениесе командалары чыкты. Шәхси беренчелектә дә Кирюшкино авылы спортчыларына тиңнәр булмады. Илнар Бикбаев, Раил Бикмәтов һәм Рамис Рафиков беренче урыннарны яулап, җиңүчеләр исеменә лаек булдылар. Шундый зур ярышларда катнашу спортчыларыбызга тәҗрибә тупларга һәм үз көчләренә ышанычларын тагын да арттырырга ярдәм итә.

ӨЛКӘ ШАХМАТ ТУРНИРЫНДА

Күптән түгел генә Иске Атлаш урта мәктәбендә якташыбыз Эльвир Якупов истәлегенә XII өлкә шахмат турниры үтте. Анда Иске Кулаткы һәм Новоспасск районнарыннан, Барыш һәм Хвалынск шәһәрләреннән командалар катнаштылар.

Шахмат уеннары алдыннан IX сыйныф укучылары батырлык үрнәге күрсәтүче авылдашыбыз Эльвир Якуповның тормыш юлы турында сөйләделәр. Әлеге чарада шулай ук аның абыйсы Абдулла Аюкаев та катнашты. Ул турнирны оештыручыларга олы рәхмәтләрен җиткерде.

Шахмат турниры швейцар системасы белән 7 турда үтте. Нәтиҗәләр буенча ирләр командалары арасында Барыш шәһәре - беренче, Хвалынск шәһәре - икенче һәм Иске Атлаш командасы өченче урынны яуладылар.

Шәхси беренчелеккә дә кызу көрәш алып барылды. Биредә Г.И. Железников (Хвалынск) - беренче, В.Г. Тюмин (Барыш) - икенче һәм Р.Ш. Давыдов(Иске Атлаш) өченче урыннарга чыктылар.

Кызлар арасында беренче урынны - Алина Габитова (Иске Атлаш), икенче урынны - Юлия Пахомова (Барыш), ә өченче урынны Алина Сайфетдинова (Иске Атлаш) яуладылар.

Шахмат турнирының тантаналы өлешен тиешле дәрәҗәдә үтүдә IX сыйныф укучылары, класс җитәкчеләре Н. Р. Чамкаева, А. Р. Калюшева зур тырышлык куйдылар һәм әлеге чараны тагын да җанландырдылар.

Өлкә турнирын оештыруда һәм материаль яктан ярдәм итүчеләргә чын күңелдән олы рәхмәтләребезне җиткерәбез.

Газинур ЮРТАЕВ,
«Ак ладья» шахмат клубы җитәкчесе.

Уважаемые работодатели!
Информируем Вас о проведении ежегодного областного конкурса «Лучший работодатель в сфере содействия занятости населения в Ульяновской области».

В соответствии с постановлением Правительства Ульяновской области от 17 августа 2016 года № 389-П «Об организации и проведении ежегодного областного конкурса «Лучший работодатель в сфере содействия занятости населения в Ульяновской области» и постановлением Правительства Ульяновской области от 24 ноября 2016 года № 553-П «О внесении изменений в постановление Правительства Ульяновской области от 17.08.2016 № 389-П» с 01 января по 10 февраля 2017 года будет осуществляться приём конкурсных материалов от работодателей для участия в ежегодном областном конкурсе «Лучший работодатель в сфере содействия занятости населения в Ульяновской области».

Участниками вышеуказанного конкурса являются организации различных организационно-правовых форм и форм собственности, а также индивидуальные предприниматели-работодатели, находящиеся на территории Ульяновской области.

Приём конкурсных материалов будет осуществляться областными государственными казёнными учреждениями Центрами занятости населения по месту фактического нахождения работодателя.

Положение о ежегодном областном конкурсе «Лучший работодатель в сфере содействия занятости населения в Ульяновской области», в том числе форма заявки и анкеты для участия в конкурсе размещены на сайте Агентства по развитию человеческого потенциала и трудовых ресурсов Ульяновской области (www.ulyanovsk-zan.ru).

Победители ежегодного областного конкурса «Лучший работодатель в сфере содействия занятости населения в Ульяновской области» будут награждены дипломами и денежной премией в размере 50000 рублей.

5 ДЕКАБРЯ - ДЕНЬ ВОИНСКОЙ СЛАВЫ РОССИИ . ДЕНЬ НАЧАЛА КОНТРНАСТУПЛЕНИЯ СОВЕТСКИХ ВОЙСК В БИТВЕ ПОД МОСКВОЙ В 1941 ГОДУ

День воинской славы России — День начала контрнаступления советских войск против немецко-фашистских войск в битве под Москвой (1941 год) — установлен Федеральным законом № 32-ФЗ от 13 марта 1995 года «О днях воинской славы (победных днях) России». Контрнаступление, как второй этап битвы за Москву, началось 5—6 декабря 1941 года на фронте от Калинина до Ельца.

Боевые действия сразу же приняли ожесточенный характер. Несмотря на отсутствие превосходства в живой силе и технических средствах, на сильные морозы, глубокий снежный покров, войска левого крыла Калининского и правого крыла Западного фронтов уже в первые дни контрнаступления прорвали оборону противника южнее Калинина и северо-западнее Москвы, перерезали железную дорогу и шоссе Калинин — Москва и освободили ряд населенных пунктов.

Одновременно с войсками, наступавшими северо-западнее Москвы, перешли в контрнаступление войска левого крыла Западного и правого крыла Юго-Западного фронтов. Сильные удары войск Красной Армии по фланговым группировкам группы армий «Центр», предназначенным для окружения Москвы, заставили немецко-фашистское командование принять меры по спасению своих войск от разгрома. 8 декабря 1941 года Гитлер подписал директиву о переходе к обороне на всем советско-германском фронте.

Успешно развивалось контрнаступление на левом крыле Западного фронта и в полосе Брянского фронта (воссоздан 18 декабря 1941 в составе 3-й, 13-й и 61-й армий; командующий генерал Я.Т. Черевиченко, член Военного совета А.Ф. Колобяков, начальник штаба генерал-майор В.Я. Колпакчи) rusevik.ru. Войска Брянского фронта во взаимодействии с войсками левого крыла Западного фронта к началу января 1942 года достигли рубежа Белев, Мценск, Верховье. Все это создавало благоприятные условия для окружения группы армий «Центр», а также сняло угрозу, нависшую над Москвой.

Победа советских войск под Москвой и начало контрнаступления имели не только огромное военное, но и политическое, международное значение – впервые во Второй мировой войны доселе непобедимый вермахт был остановлен и потерпел весомое поражение. А сегодня дата 5 декабря – ещё один повод вспомнить героев той войны...

В День воинской славы в нашем районе прошло памятное мероприятие. В нем приняли участие школьники, учителя, коллективы детских садов, администрации и других организаций. Участники мероприятия почтили память героев минутой молчания, возложили венок к обелиску Славы.

ПРОФЕССИОНАЛЬ МАСТЕРЛАР КОНКУРСЫНДА

Соңгы елларда Ульяновск өлкәсендә хезмәт кешесенең статусын күтәрү буенча төрле чаралар үткәрелә. Мәсәлән, өлкә Губернаторы С. И. Морозовның инициативасы белән 2013 елдан Россия Федерациясенең беренче субъектлары буларак «Яшь профессионаллар» WorldSkills Russia дип исемләнгән региональ чемпионат оештырылды. Бу чемпионат эшче профессияләрне популярлаштыру һәм прфессиональ әзерлек стандартларының статусын күтәрүдә зур роль уйный.

Шушы нигездә безнең Иске Кулаткы дәүләт механика-технология колледжында даими рәвештә зур чаралар үтеп тора.

15 – 18 октябрь көннәрендә әлеге уку йортында профессиональ мастерлыкны күрсәтү буенча «Алтын куллар мастеры» дип исемләнгән өлкә конкурсының башлангыч этабы үтте. Анда «Автомобиль транспортына ремонт һәм техник хезмәт күрсәтү», «Веб дизайнер» профессияләре буенча конкурслар оештырылды. Әлеге бәйгедә Ульяновск өлкәсенең 15 уку йортының вәкилләре теория һәм практика буенча үзләренең осталыкларын күрсәттеләр.

«Автомобиль транспортына ремонт һәм техник хезмәт күрсәтү» компетенциясендә студентлар Р. Давыдов, Р. Морозов, К. Мехтиев тиңдәшле рәвештә беренче, икенче һәм өченче урыннарны яуладылар. Ә «Веб дизайн» компетенциясендә студентлар А. Прунов - беренче, Р. Байбиков - икенче, А. Сөләйманов өченче урыннарга чыктылар.

Бу конкурста Иске Кулаткы беренче һәм икенче номерлы урта мәктәпләренең укучылары җанатарлар буларак конкурсантларга җиңү яуларга көч һәм дәрт бирделәр.

28 ноябрьдән 2 декабрьгә кадәр Ульяновск шәһәрендә эшче профессияләр буенча V региональ чемпионаты үтте. Бу бәйгедә безнең студентлар да үзләренең җитезлекләрен күрсәттеләр. Анда «Автомобильләргә ремонт һәм хезмәт күрсәтү» компетенциясендә Иске Кулаткы дәүләт механика-технология колледжының студенты Радик Давыдов җиңүче булып чыкты.

Региональ чемпионатта 160 тан артык студент катнашты. Хәтта Ярославль, Владимир шәһәрләреннән-катнашучылар да булды. Әлеге бәйгедә беренче мәртәбә Оренбург, Казан, Яр Чалы, Новосибирск, Краснодар, Пермь шәһәрләреннән, Мәскәү өлкәсеннән һәм Мордовиядән сертификатлы экспертлар эшләделәр.

Иске Кулаткы дәүләт



механика-технология колледжы студенты Радик Давыдовның региональ чемпионатта беренче урынга чыгуы безнең районыбызда яшәүчеләрнең күңелендә зур горурлык хисләре уята. Ул тиздән Казан шәһәрендә үтәчәк Бөтенроссия чемпионатында да катнашачак. Без аңа уңышлар һәм бу бәйгедә дә җиңеп чыгуын теләп калабыз.

Рөстәм АРИФУЛЛИН.

БЕРГӘЛӘП УКЫЙБЫЗ

ÊÖÒÅÏ ÓÇÃÀÍ ÃÎÌÅÐ

Повесть

Зифа Кадырова

Тормышта болар барысы да бик кирәк булачак, әзрәк татар теле дә өйрәтсәң дә зыян итмәс иде. Рушания үз чирен онытып, бөтенләй башка хыялга кереп китте, кызының киләчәген матур итеп күзалларга тырышты. Аның киләчәге әнисе салган тәрбия нигезенә бәйле, ул да әнисеннән ни өйрәнсә, үз гаиләсендә шуны кабатлаячак. Алар икәүләшеп шәһәрдән тукымалар алып кайтып, күлмәк тектеләр. Вак кына зәңгәр чәчкә төшкән җиңсез күлмәкне Рушания кызының тез өстеннән, нечкә билен матур итеп бөреп, киң итәкле итеп текте. Бу аның яшь чагын хәтерләтә иде, аның әнисе оста тегүче иде, Рушаниягә дә унҗиде яшенә шундый күлмәк тегеп кидергән иде. Алеся көзге алдында әйләнде.

- Әни, матурлыгын матур, тик бигрәк авылча, кызлар көлмәс микән?

- Ә синең кемгә ныграк ошыйсың килә, кызларгамы, Айраткамы?

- Әни, үзең беләсең бит инде.

- Шулай булгач, борчылма. Кара, күзләреңә ничек килешә, ә билеңне нинди матур итеп сызып төшә. Минем дә шундый күлмәгем бар иде, әтиең, беләсеңме, нинди сокланып карый иде?! Ә хәзер кендек күрсәтеп йөриләр, бу нәрсә ничек тә башка сыя торган нәрсә түгел. Хатын-кызда сер булырга тиеш, ә ул бөтен җирне чишеп күрсәткәч, нинди сере калсын ди. Элекке заманда беләкнең ак йомшак җирен күрсәләр дә, ирләр ах иткәннәр. Кызлар сер сандыгы булганнар, ә ирләр шул серне гомер буе сүткәннәр. Хәзер нигә мәхәббәт юк дисез, чәнки сер юк. Әнә, урамга чык та кара, сере дә юк, сүтәр әйбере дә юк, ул инде сүтелеп беткән. Хатын-кыз серле булып, бер генә кешегә ачылырга тиеш, кызлар әрсез, азгын карашлардан сакланырга тиеш. Яман күзләр бар, кул белән кагылмасалар да, күз белән күпме ир-ат капшый ул яшь тәнне, бөтен кеше капшап беткәч, кемнең өйләнәсе килсен? Салкын тию бар, сакланмыйлар, аннан бала таба алмыйлар, кеше ташлаган балалар эзләп йөриләр, чәнки бала тапмаган хатын - җимеш бирмәгән агач ул, исеңнән чыгарма, балам.

Алеся берсүзсез әнисен тыңлап утыра бирде. Менә нигә әнисе башкаларга охшамаган, ул чынлап та серле хатын иде, аның хәтта баш борылышларына, торып китүләренә чаклы ниндидер серлелек бар. Алеся әнисенә карап утырды да, килеп муенына сарылды.

- Син иң серле әни! Элек без синең белән бер дә болай ачылып сөйләшкәнебез булмады, ә нинди рәхәт болай серләшеп утыру, - дип әнисенең битеннән үбеп алды.

Алеся бергә укыган группасын кунакка чакырды, Айратка да килми калма, диде. Үзе белән укыган бер егеткә калдырмаска, үзе белән алып килергә кушты, Алеся бу көнгә бик зур өметләр баглый иде. Рушания да кызыннан ким дулкынланмады, әйтерсең, аның язмышы хәл ителә. Төштән соң яшьләр җыела башлады, ә көткән кеше һаман күренмәде, инде бөтен курс җыелып бетте. Алесяның кәефе кырылганнан-кырылды, күзендә яшь тә ялтырый башлады. Яшьләр бакчада шау-гөр килделәр, ә Алеся әнисе яныннан өйдән чыгасы килмәде. Шулчак сакчы телефонга шалтыратты: «Монда тагын берәү килде, кертергәме?»

- Кертергә-кертергә, - диде кабаланып, үзе тәрәзәгә ташланды. Капкадан киң җилкәле, хәйран гына гәүдәле, карап торуга әллә ни чибәр дә булмаган бер егет керде. Кая барырга белмичә, тирә-ягына каранып тора башлады.

- Кызым, бу кем?

Алесяның йөзе кып-кызыл булды, кабынып киткән лампочка кебек йөзе яктырып ук китте.

- Әни, бу бит Айрат, - диде дулкынланып.

- Чү, тыныч лан, бар, өйгә чакыр.

- Алеся инде чыгып чабарга җыенган иде, Рушания кызын туктатты.

- Килешми алай ир-атка ташлану, үзеңне кулга ал.

Тик кызының куллары калтырый, кая куярга белми җәфалана, шулай да ул бит Рушания кызы - үз-үзен кулга алып, кунакка каршы чыкты. Кызының дулкынлануы аңа да күчте, «эх, яшьлек, эх, бала»,- дип куйды әнисе.

- Мама, бу Айрат, - диде кызы. Рушания бик матур итеп елмаеп:

- Исәнмесез, Айрат, узыгыз, - диде матур итеп татарча. Айрат аптырап, бер Рушаниягә, бер Алесяга карады.

- Исәнмесез, апа.

- Мин Рушания апа булам, - дип тагын матур итеп елмайды. - Әйдә, узыгыз, сез азрак соңга калдыгыз, башкалар ашап-эчеп чыгып киттеләр инде.

- Ә мин эзләп йөрдем, сорый-сорый көчкә таптым.

Рушания бу олпат гәүдәле егетне астан гына күзәтте: әллә ни чибәр булмаса да, аңарда көчле ирләргә генә хас эчке рухи көч һәм беркемгә дә охшамаган үҗәтлек сизелә иде.

- Кызым, аш сал кунакка.

- Гафу итегез, мин сезне мөселман гаиләседер дип белмәдем.

- Безнең әтиебез урыс, - дип елмайды Рушания. - Мин генә мөселман.

Егет каршысында утырган Алесяга ниндидер аптыраган караш белән, кабат беренче күргәндәй карап куйды.

- Аңлашыла, - диде алдындагы ашка карап. Рушания юкны бар итеп чыгып китәргә ашыкты, икесен генә калдырырга булды.

- Сез ашагыз, минем эшләрем бар, - дип бакчага чыгып китте.

Яшьләр җыелышып, Кама буена су керергә төшеп киттеләр, Рушания кабат үзенең яраткан атынчыгына килеп утырды, уйга чумды, ул кабат-кабат әле килгән егет турында уйлады. Уйлана торгач, бер нәрсәне аңлады: үзе исән чакта кызын ышанычлы кеше кулында күрәсе килде, бәлки әле әби булырга да өлгерер. Уйларын кинәт ят тавыш бүлде, ул сискәнеп китте.

- Рәхмәт, Рушания апа, бәлешегез бик тәмле булды.

- Бәлеш өчен рәхмәтеңне Алесяга әйт, ул пешерде.

Егет тагын беренче күргән кебек итеп кызга карап куйды. Аның янында торган кыз бер әнисенә, бер егеткә карады. Рушания елмаеп:

- Аңлыйсың килсә, кызым, татарча өйрәнергә туры килә, диде русчалап. - Утыр, Айрат улым, - дип яныннан урын бирде. Мин шушында уйланып утырырга яратам, безнең бу бөтенебезнең дә яраткан урыныбыз.

- Бик матур монда, бакчагыз да бик зур, кем карый боларны?

- Без карыйбыз, менә әтисе эштән кайта да, бакчага чыга, улым да. Ирләр казыйлар, тирес кертәләр, без Алеся белән утыртабыз, утыйбыз, су сибәбез, безнең өчен беркемдә эшләми. Эшләмәсәң, бер нәрсә дә булмый, улым, - дип елмайды үзен дикъкать белән тыңлап утырган егеткә.

- Дөрес әйтәсез, апа, мин дә шул уйда. Безнең дә бакча бар, зур түгел, дүрт сутый гына, безгә җитә, урламасалар.

- Ә син кем белән яшисең?

- Мин, әни һәм сеңелем белән.

Аның астан гына Алесяны күзәткәнен Рушания күреп утырды, ахрысы, ул үзе дә ошата иде Алесяны. Тик бөтен кеше дә байлар белән туганлашасы килми шул, тиң түгел дип саныйлар. Алеся авызына су капкандай шым гына утыра бирде, күбрәк Рушания сөйләште. Күреп тора егетнең карашы үзгәргәнне: байлар эш эшләми, шоколад кына ашап утыралар, дип уйлагандыр.

- Кызым, бар, Айратка тиеннәрне күрсәт, менә, чикләвек тә ал, ашатырсың.

Яшьләр бакча читенә киттеләр, Рушания бик канәгать елмаеп куйды.

Бер атнадан кызы башка студентлар белән чит илгә эшкә китте, китәр алдыннан ул әнисен кочаклап:

- Әни, рәхмәт, синдәй әниләр җир йөзендә юк, син иң чибәр, иң серле әни, иң акыллы! - диде.

- Сиңа ни булды, кызым? Бер юлга бик күп түгелме? - дип елмайды.

- Син булмасаң, мин һаман Айрат белән аңлаша алмыйча газап чигәр идем әле. Ул сине, «әниең шундый чибәр, искитмәле хатын», диде. Аннан, әни, синең биргән киңәшләрең дә нәкъ син әйткәнчә булып чыкты, Айрат күлмәгең бик килешә», -диде.

Алесяны иртәгә китә дигән көнне, кич белән, капка төбендә бер роза чәчәге тоткан Айрат көтеп тора иде.

Июнь ахырына Рушанияне тагын Илья Ильич чакыртып алды. Анализлар алгач:

- Берәр атна капельница алырга туры килер, ничек тә йөрергә тырышыгыз, бу сезнең өчен бик кирәкле дарулар, - диде.

Рушания иртән Сашага:

- Мин әзрәк массажга йөреп алам, мине югалтма, Самат йөртер, -дип кисәтеп куйды. Сашасы каршы килмәде. Кисәтеп куйгач, үзенә дә тыныч иде. Иртән Илья Ильич үзе каршы алды, мөлаем итеп елмайды.

- Мин инде килмәссез дип курыккан идем.

- Сезгә каршы килеп буламы соң? - дип елмайды Рушания.

- Күрәм, кәефегез дә бик яхшы күренә.

- Мин сезгә ышанам, сез яхшы дигәч, яхшы инде алайса.

- Ышаныгыз, бар да яхшы булыр, һәрвакыт яхшыга гына өметләнергә кирәк.

Рушанияне бер палатаның буш койкасына кертеп урнаштырдылар. Ул кереп ятуга, каталка белән бер хатынны алып керделәр дә ипләп кенә койкага күчереп салдылар. Теге хатын ыңгырашып куйды, аның күкрәге кысып бәйләнгән иде. Рушания ул якка карамаска тырышты. Йөри алганнар торып, аның янына җыелдылар, ул бер кулы белән һаман күкрәген капшамакчы булды, үзе елый-елый ирен чакырды. Ире:

- Мин монда, елама, бар да яхшы, - дип, аның кулларын кысып тотты. Палатага Илья Ильич белән тагын бер табиб килеп керде.

- Сезнең бар да яхшы, операция бик уңышлы үтте, борчылырлык бернәрсә дә юк.

Теге хатынның ире күзләрендәге яшьләрне яшерә алмады, килеп докторның кулларын кысты.

- Рәхмәт яхшы сүзегезгә, рәхмәт, - диде дә хатыны ята торган карават кырыена тезләнде. Аннан Рушаниягә да чират җитте, аңа да берничә шешә дару китереп куйдылар. Моны күзәтеп торган Илья Ильич:

- Бу сезнең организмны чиргә каршы торырга булышачак, тыныч кына ятыгыз, йоклап алсагыз да була, - диде.

Бераз торгач, шәфкать туташы кереп, Рушаниянең беләкләренә әнәләрне ялгап чыгып китте. Бу шулай тыныч кына атна буе барды. Илья Ильич та «бар да яхшы», диде.

Шулай даике атнага бер күренеп торырга кушты. Рушания кабат кайтып үз бакчасына бикләнде, монда тыныч, рәхәт иде, ул шәһәрләрдә ничек яшиләрдер.

Беркөнне Саша эштән кайткач:

- Әйдә, әнисе, берәр җиргә ял итәргә барабыз, җитәр бу дүрт стенада бикләнеп ятарга, - диде. Рушания моңа шатланып та куйды, тик шулай да доктордан сорарга булды. Ул:«Кирәкмәс, самолетта очу, юл йөрү авыр булачак, һәрхәлдә, җәйге эссене кичерү авыр булыр» дигәч, Рушания кире какты. Кызынырга ярамый, озак йөри алмый, ә болай ярыйсы - үзен начар хис итми. Болай гына торса, хәле ишәрлек. «Тагын бер ун ел гына яшәргә иде ичмаса», - дип хыялланып куйды Рушания. Саша бертуктаусыз Мәскәүгә командировкаларга очты, әтиләре өйдә юк чакта улы әтисенең эшләрен алып бара. Саша улына ышанып, күп кенә ипләрне аңа тапшыра, үзенә алмаш җитәкче үстерә. Игорь әтисе юк чакта әнисен берүзен генә калдырмады, алар икесе кичләр буе бакчада сөйләшеп, чәйләр эчеп утыралар. Шулай да Рушания җае чыкканда, үзен кызыксындырган сорауны биреп калырга булды.

- Улым, синең йөргән кызың бармы? Бәлки өйләнерсең?

Игорь бик җитди итеп әнисенә карап торды.

- Өйләнер өчен сезнең кебек чын-чынлап яратырга кирәк, ә мин әле гашыйк та булганым юк.

- Улым, тирә-ягыңа әйләнеп кара, күпме чибәр-чибәр кызлар, бәлки, бик нык сайлыйсыңдыр, сиңа ниндирәк кызлар ошый соң?

- Нинди дип, синең кебек тыйнак, йомшак, синең кебек серле. Ә хәзер кызлар артык кыюлар, күзгә тузан булып керәләр, эчәләр, тарталар. Бөтенесе дә дип әйтмим, әмма күбесе. Карап торуга шундый чибәр кыз, курчак кебек, ә авызын ачып ике сүз әйтсә - аңлашыла: тозсыз кара надан, башында акчадан башка берни дә юк. Тәмәкесен суыра, сырасын чөмерә, бер эш белмиләр, ә сөйләшүләрен тыңлап торсаң, косасылар килә. Кайдан килә бу чаклы тәрбиясезлек, Исең-акылың китәр. Ул бит, әни, акчасызларда гына түгел, акчалысында да шул ук хәл.

- Куй, улым, барысы да алай син уйлаганча начар булмас, бәлки син үзең шундый җирләрдә йөрисеңдер, сеңелең бит андый түгел, ул да бит шул кызлар рәтенә керә.

- Аны бит син тәрбияләдең, әни, ә андый кызларны күрер өчен әллә кая йөрергә кирәкми, әнә, безнең компаниядә эшләгәннәр дә җитәрлек, биш минут саен тәмәке тартырга йөгерәләр. Мин менә монда синең урында кемнеңдер тәмәке тартып, төкеренеп утырганын күзалдыма да китерә алмыйм. Әти тартмады, мин дә тартмыйм, син дә эчмисең дә, тартмыйсың да. Мин дә үз хатынымның синең кебек булуын телим. Теге Антоновларга барсаң, бөтенесе өй буйлап тәмәке күтәреп йөриләр. Әт, песи, төтен - керсәң, тизрәк чыгып качасы килә. Әниләренең һәрвакыт авызында -тәмәке, кулында - сыра, кызлары да шул ук, сыра эчә-эчә симереп беткән. Син уйлама безне берни дә аңламый дип, мин үз гаиләм белән бик тә горурланам, син шундый тәртипле булганга, без дә шундый. Беләсеңме, әни, хәзер бик күп егетләр үзләренә хатынны мәчеттән эзлиләр, әнә теге төренеп йөри торган кызлар арасыннан.

Рушаниянең күзе шардай булды.

- Ничек, кем кертә сезне анда?

- Анда керү ирекле. Алар янына бармыйсың, читтән генә күзәтәсең. Хәзер, әни, мәчет алларында, беләсеңме, күпме кыйммәтле машиналар тора, әллә син намаз укырга киләләр дип беләсеңме? Бай-бай егетләр үзләренә хатынлыкка шуннан кыз эзлиләр. Син шәһәргә чыгып йөрмәгәч, бернәрсә дә белмисең шул. Безгә килгән минем иптәш егетләр дә сиңа карыйлар да, татарочка алырга кирәк, диләр.

- Нигә, улым, урыс егетләре дә мәчеттән эзлимени кәләшне?

- Эзли, нигә эзләмәсен. Урыс халкы нык эчкечелек белән мавыга, каннары бозылып беткән, ә яхшы нәсел калдырасың килсә, сау-сәламәт балалар үстерәсең килсә, азмаган, каны сыра белән бозылмаган сау-сәламәт ана кирәк. Хәзер бит, әни, күпләр ислам дине белән кызыксына. Анда бик күп нәрсәләр христиан диненнән аерылып тора, күп нәрсәләр тыела, син бит менә аларның барысын да беләсең.

- Мин, улым, беркайчан да мәчеткә йөрмәдем, мине әбиең шулай тәрбияләде. Артык кычкырып сөйләшмә, кеше алдында кычкырып көлмә, ир-атның күзенә текәлеп карама, иреңне һәрвакыт елмаеп каршы ал, ул тапканны җыйнак итеп тота бел, ирең читкә йөрмәсен дисәң, ул теләгәнне канәгатьләндерә бел, аны бер күз карашыннан аңла. Кеше килгәндә, балаларың шаулашып өстәлгә менмәсеннәр, кешегә ач күзләре белән карап тормасыннар, балаларың тук, баш яулыгың белән алъяпкычың чиста булса, йөзең ак булыр - менә шулар, әллә ни сере дә юк.

- Син шулай дисең, әни, миңа менә күп кенә дус егетләргә керергә туры килә, тик берәүдә дә бездәге кебек тәмле аш исе килеп тормый. Тукланалар шунда юк-бар колбаса, кәбестә белән. Ә безнең өйгә кайтып керү белән тәмле токмачлы аш исе, пешкән камыр, бәлеш исләре, безнең өйгә таралган тәмле хуш исләр бернигә алыштыргысыз. Кайда барсаң да, өйгә кайтасы килеп тора, озаграк читтә йөрсәң, шул исләрне сагынасың. Ул исләр белән бергә сине күзалдына китерәсең. Менә шуңа да әти читтә синнән башка озак тора алмый.

Рушания канәгать елмаеп куйды. Менә ничек икән бит. Ул көндәлек тормыш кына алып барам дип уйлады, ә балалары аны һәрвакыт күзәтеп, һәрнәрсәне күңелләренә сеңдереп үскәннәр. Өметсез түгел, дөньяны бик яхшы аңлыйлар икән бит.

- Улым, мине дә берәр көн мәчеткә алып бар әле, бер дә кергәнем юк.

- Кайчан телисең, әни, шунда алып барам.

- Әтиең кайтканчы берәр көн иркенләп йөреп кайтыйк әле. Иртәгә кече атна түгелме соң, әйдә, вакытың булса, төштән соң барып кайтыйк.

- Ничек теләсәң - шулай булыр, әни.

Икенче көнне Игорь кайтып туктады, төшке ашны ашадылар да, җыенып чыгып киттеләр. Рушания башына ак яулык бәйләде, озын итәкле күлмәген киде, ул үзенең бик дулкынлануын тоеп, Ильич биргән даруны кабып куйды. Аны улы ГЭС бистәсенең иң зур мәчетенә алып килде, чынлап та, мәчет алдында хәйран гына матур-матур машиналар тора иде. Мәчеткә башларына яулыклар бәйләгән, озын-озын итәк кигән кызлар, олы-олы апалар агыла.

- Әни, әнә, кара, Серёга утыра, ул һәр җомга шушында килә, кызлар күзли. Берсе дә күтәрелеп карамыйлар, ди. Башларын иеп кенә, үтеп китәләр, ди, шулай да арасында берсен сайлаган инде, шуны күзли.

- Урыс дип әти-әниләре бирмәсә?

- Керәшен бит ул, аңа тегеләй дә, болай да ярый. Әни, бар, кер. Курыксаң, бергә керәбез.

- Әйе шул, улым, әйдә, бергә керик, мин кай тарафка барырга да белмим, бик дулкынланам.

Алар ашыкмыйча гына алга атладылар. Олы мәчеткә керүгә, ул хәйран калып катып калды. Аның мәчеткә беренче керүе иде. Чиркәүдә булганы бар, чукынырга кермәсә дә, андагы стена-түшәм тулы сүрәтләрне карарга бик ярата. Чиркәүләрдә тонык, караңгырак булса, монда биек һәм ап-ак, яп-якты.

- Узыгыз-уз, менә монда аяк киемнәрегезне салыгыз да узыгыз, сорауларыгыз булса, сорагыз.

- Рәхмәт, бабакай, без беренче тапкыр мәчеттә. Мине үстергән әнием-әтиемне искә алып, - диде дә төртелеп калды, ничек дөрес итеп аңлатырга белмәде. Бабай аның хәлен аңлады, ахрысы.

- Яхшы, балалар, утырыгыз шушында. Кем атлы әни- әтиең?

- Айбикә белән Барый исемле ләр иде, бабакай.

- Ярый, бик яхшы. Әйдәгез, балалар, Айбикә белән Барыйны искә алып, хәер-фатыйха кылыйк. Сез бик дөрес эшләгәнсез бүген килеп, чөнки безнең арадан киткән ата-аналарыбыз, әби-бабаларыбыз һәр атна кич хәер-дога өмет итеп кайтырлар ди. Шуңа күрә һәр пәнҗешәмбе дога укып, арадан киткән якыннарыгызны искә алырга онытмагыз. Кемнәрне искә алганнар, аларны искә алып хәер-дога кылганнар - шулар сөенерләр, йөзләре якты булыр, дигән Ходай. Ә кемнәр бу көнне хәер-догасыз калган, алар көтәрләр-көтәрләр дә, безне онуттылар дип рәнҗеп, кире китәрләр, ди. Кеше атна саен мәчеткә килә алмаска да мөмкин, шуңа күрә ул үзеннән соң Коръәнне аңлап укырлык, дога кылырлык бала, нәсел калдырырга тиеш. Ә Коръәнне укып чыккан кеше инде харамнан да, азгынлык белән шакшылыктан да ерак тора, аңлашылдымы? Ярый аңлашылса, әйдәгез, бездән хәер өмет иткән әрвахларга, - дип бабай укып китте.

Башта Коръән телендә, аннан шул укыганын татар телендә тәрҗемә итеп чыкты. Рушаниянең үзе дә сизмәстән бите буйлап күз яшьләре акты, күз яшьләре күрсәтеп, беркайчан да кеше алдында елаганы юк иде, ә хәзер менә ул үзен тыярга да, тыелырга да уйламады. Ул укыган мулланың баш очына карады, аның артында ак яулыклы әнисе елмаеп басып тора иде. Рушаниянең дә акрын гына ирәннәре селкенде. Кичер, әнием, ничә атналар, күпме еллар кайткансыңдыр шушы көнне, шушы хәер-доганы өмет итеп. Күпме тапкырлар башыңны иеп, хәер-догасыз кире киткәнсеңдер, онытты бердәнбер балам дип рәнҗегәнсеңдер.

Мулла абзый укып бетереп битен сыйпады да Рушаниягә бик дикъкать белән карап алды.

- Сине, балам, нәрсәдер бик борчый. Бәлки, син бүген кайбер нәрсәләргә башка күзлектән карагансыңдыр, Ходайның кодрәте киң, балам, борчыган борчылуларың шушы күз яше белән юылып төшсен, җаныңа тынычлык урнашсын.

Дәвамы бар.

ТӘБРИКЛӘҮ КАБУЛ ИТЕГЕЗ!

Кадерле хезмәт ветераннары, өлкән буын вәкилләре!

Районыбызда гомер кичерүче хезмәт ветераннары Зәйтүнә Зәкәрьевна Абдульмәнова (Югары Терешка), Нурҗиһан Хәлиловна Абитова (Яңа Зимница), Хәдичә Иматевна Бахтеева (Иске Кулаткы), Рәшит Исхакович Бикбаев (Вязовый Гай), Галия Яхъевна Бәширова (Вязовый Гай), Сафия Абдулхаковна Деникаева (Иске Кулаткы), Бибиҗан Алихановна Иксанова (Вязовый Гай), Мөнирә Хәсәиновна Люкманова (Иске Кулаткы), Зәкия Абдулхаковна Мостафина (Кирюшкино), Зәгидулла Мусеевич Рәхимов (Карамалы), Шикур Ахатович Хәсәнов (Иске Кулаткы), Расимә Ибраһимовна Яфарова (Яңа Кулаткы) 2016 елның декабрь аенда үзләренең истәлекле 70 яшьлек юбилейларын билгеләп үтәләр.

Район ветераннар Советы Сезгә истәлекле юбилейларыгыз уңаеннан фидакарь хезмәтегез, ихтыяр көчегез, районыбызга булган ихлас мәхәббәтегез өчен рәхмәт һәм хөрмәт сүзләрен, котлауларын җиткерә! Сезгә чын күңелдән нык сәламәтлек, тынычлык, иминлек һәм бетмәс-төкәнмәс тормыш энергиясе телибез! Сезнең тормышта шатлыклы очрашулар күп булсын, туганнарыгыз һәм якыннарыгыз күңел җылысы белән шатландырып, Сезнең турында һәрвакыт кайгыртып, игътибар күрсәтеп яшәсен!

БЕЗДӘН - КИҢӘШ, СЕЗДӘН - ЭШ

Татар халкы элек-электән кабак белән дус-тату яшәгән. Әле күчмә тормыш рәвешен алып барганда да борынгы бабаларыбыз – төркиләрнең төп ашау ризыгы – ит булган. Билгеле ки, ит ашказаны өчен шактый майлы, авыр ризык. Ә кабак майны сеңдерә алуы белән билгеле. Моннан тыш кабак бик тиз һәм җиңел эшкәртелә. Кабакның бер генә әйбере дә әрәм булмый, төшләрен кыздырып ашау тәмле генә түгел, файдалы да.

Кабакны эчен арытып әзерләп куйгач, аңа эчлек әзерләргә кирәк. Моның өчен сарык, үрдәк яки каз итен сайлыйлар. Итне эрерәк кисәкләргә турап аерым савытка салып куялар. Кош итен сәякләреннән аерып тормыйлар икән. Икенче бер савытка

яхшылап юылган һәм бераз гына бүрттерелгән дөге, яки карабодай салына. Тагын туралган суган, тоз, уылган борыч, лавр яфрагы һәм кара җимеш тә әзерләп куярга кирәк.

Кабакның капкачын ачып, эченә башта ит, соңыннан ярма, өстенә суган, тәмләткечләр һәм җимеш салалар. Барысын бергә тутыргач, өстенә кайнаган су да салына. Тутырган кабак әзер! Хәзер аны кайнар духовкага тыгып пешерәсе генә кала. Ризыкның әзер булу-булмавын тикшерү өчен аның капкачын ачып, эчендәге әйберләрен кабып карарга мөмкин. Нигездә. Уртача зурлыктагы тутырган кабак 2-2,5 сәгать дигәндә пешеп тә чыга.

Пешкән кабакны өстәлгә алып куйгач, аның капкачын ачалар да, зур кашык белән эчендәге әйберләрен болгаталар. Бу вакытта алдан салынган дөге, ит һәм суган белән бергә кабак үзе дә кушылып бетә. Тутырган кабакны өстәлгә бөтен килеш куялар да, табында утыручылар үзләренә күпме кирәк, шуңын кадәр салып ашыйлар.

Уртача зурлыктагы бер кабакка: 500-600 грамм туралган ит, 150-200 грамм тирәсе бүрттерелгән ярма, 2-3 кечерәк кенә суган, унлап кара җимеш, бер стакан кайнаган су, тоз, борыч, 3-4 лавр яфрагы.

Гөбәдия пешерү рецепты

Гөбәдия өчен камыр ясау:

Майлылыгы 15 процентлы 1 литр каймак, 6 йомырка, 1 аш кашыгы тоз, 3 уч шикәр комы (120 г тирәсе), 80 г чүпрә (коры чүпрә ярамый, камырны начар кабарта икән), 200 г акмай, 50-60 г үсемлек мае. 1 литр сыеклыкка 2 кг исәбеннән он алына. Онны салганчы, сыеклыкны чак кына җылытып алырга кирәк.

Май камырны басып бетерер алдыннан гына салына. Басканнан соң камырның бераз кабарганын көтәргә кирәк. Бу кадәр камырдан өч таба гөбәдия чыга.

Эчлеген ясау:

(бер таба гөбәдиягә)

1 стакан тулыр-тулмас дөге, 5 йомырка (кабыгы әрчелгән йомырканы тозга манып алып, эре угычтан уалар), 1 стакан йөзем җимеше, 300 г корт, 350 г акмай. Эчлек катлы-катлы итеп салына. Акмайны йөзем өстенә түшәп чыгалар. Гөбәдиянең аскы ягына – 500 г, өске ягына 200 г камыр кирәк.

МАТБУГАТ САЙТЫННАН АЛЫНГАН.

ПЛАСТИКОВЫЕ ОКНА

Производство и установка пластиковых окон.

При заказе пяти окон, шестое – бесплатно! Замер, доставка – бесплатно.

Наше качество и доступные цены порадуют вас! Пенсионерам – дополнительная скидка!

20% скидка

Телефон: 8-937-278-05-55.
Павловка.

ПЛАСТИКОВЫЕ ОКНА от производителя. НАТЯЖНЫЕ ПОТОЛКИ НЕДОРОГО. РАССРОЧКА. Просто позвони. Телефон: 89272125484.

В магазине "Сим-Сим" АКЦИЯ - качественная мебель по низким ценам. Диваны – от 7400 руб. Кухонные гарнитуры – от 6900 руб. Кровать с двухсторонним пружинным матрасом – от 5400 руб. Прихожие – 3950 руб. Уголки школьника – 3497 руб. Комоды и столы-книжки – 2288 руб. Мебель в наличии и на заказ. Мы находимся по адресу: р.п. Новоспасское на площади Макаренко, ул. Терешковой, 22 а. Телефон для справок: 89278230001.

Стоматология ООО «Дента Люкс»

приглашает вас воспользоваться качественными услугами современной стоматологии

пациентам нуждающимися в протезировании готовы предложить:

- съемное протезирование: протезы из акриловых пластмасс, бюгельные, нейлоновые;

- несъемное протезирование: коронки с покрытием, металлокерамические, комбинированные, цельнолитые и.т.д.

Запись предварительно по тел.: 89278033404, Пионерская, 18 А. Консультация бесплатно.

Скорая компьютерная помощь

ИП «Шафиева» предоставляет услуги по установке, настройке, а также по ремонту компьютерной технике.

Профессиональный ремонт компьютеров и ноутбуков.

Установка WindowsXP/7/8/10; Удаление вирусов, установка антивирусника; Очистка от пыли и грязи при перегреве; Оптимизация работы компьютера и многое другое. Выезжаю в села, работаю с организациями. Цены приемлемые. Действует скидочная система. Заказы принимаются круглосуточно.

Мы находимся по адресу: р.п. Старая Кулатка, в здании магазина «Магнит» на втором этаже, 1 павильон слева. Звоните по телефону: 89279837788 (Марс).

Организация реализует кур-несушек с доставкой на дом. Тел.: 89298156785.

Продается автомобиль «Lifan Solano» 2013 года выпуска, цвет – черный, люкс, в отличном состоянии. Телефон: 89378817478 – Павел.

Продается массажное кресло-кровать «RestArt" с 49-ю нефритами, модель RK-3101, в отличном состоянии. Телефон для справок: 89378817478 – Павел.

Продается деревенское, индюшиное мясо халяль. Тушки - от 4 кг. Цена – от 280 руб. Также в продаже: пшеница, жмых, фураж. Недорого. Телефон для справок: 89278093172.

В р.п. Старая Кулатка продается: подсолнечник - 20-25 руб. за кг, жмых – 14 руб. за кг., пшеница - 10 руб. за кг., просо – 10 руб. за кг., овес – 8 руб. за кг., тыква – 10 руб. за кг., а также дрова – недорого. Телефон: 89276344799.

Требуется продавец в магазин продукты «Ермолино». Телефон для справок: 89379823935.

13 декабря с 10 до 11 час. в РДК-ул. Куйбышева,20

СЛУХОВЫЕ АППАРАТЫ

Усилители до 5500 р, заушные от 6900 р
цифровые и сверхмощные от 14000 р
Дания, Германия 15500 - 17000р
Акция! Сдай старый аппарат-получи скидку на новый до 2500р!
Выезд по району и условия акции по телефону
тел. 8-922-503-63-15
(звонить предворительно, в рабочее время)
имеются противопоказания.
необходима консультация специалиста
Св №305183220300021 ИП Коробейникова Е.М.

Магазин «Гранит»

- ритуальные ограды – от 3000 тыс. руб.
- таблички на ограды – от 600 руб.
- памятники – от 7000 тыс. руб.
Бесплатная доставка.
Изготовление памятников участникам ВОВ – бесплатно.
Телефон:
8 – 904 – 196 – 09 – 18. Ринас.

Район үзәкләштерелгән китапханә хезмәткәрләре тормыш иптәше **Якуб Алимҗанович БӘШИРОВНЫҢ** вафат булуы сәбәпле, Вязовый Гай авылының китапханәчесе Халидә Яхьевна Бәшированың тирән кайгысын уртаклашалар.

Вязовый Гай авылы мәдәният йорты хезмәткәрләре тормыш иптәше **Якуб Алимҗанович БӘШИРОВНЫҢ** вәфәт булуы сәбәпле, китапханәче Халидә Яхьевна Бәшированың тирән кайгысын уртаклашалар.

Директор - баш редактор М.С. МАСИЕВА.

Адрес редакции, издателя: 433940 р.п. Старая Кулатка Ульяновской области, ул. Куйбышева, 22. ОАУ Редакция газеты "Кумяк кюч".

Телефоннар:
электрон адрес: **kumiakk@mail.ru**
884(249)2-11-94-редактор, факс, бухгалтерия;
884(249)2-12-64 - журнали - стлар, реклама бүлеге, РИК операторлары.

Индекс 54505.
Газетаны басарга кул кую вакыты: график буенча - 16.00 фактта - 16.00
Тираж 2600
Заказ № 13/49
Распространяется по подписке.

Газета отпечатана с готового оригинала-макета в ООО «Принт Хаус» 432071, г. Ульяновск, ул. Федерации, 15.

Элемтә һәм масса - күләм коммуникацияләр сферасында күзәтү буенча Федераль службаның Ульяновск өлкә идарәсе 2014 елның 21 ноябрендә ПИ №ТУ73-00388 номерлы масса-күләм информация чарасын регистрацияләү таныклыгы белән регистрацияләнде.

Газета битләренә урнаштырылган рекламалар һәм белдерүләр өчен редакция җаваплылык тотмый.

Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Хатлар, кулъязмалар һәм рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.